*(Башкалар да табакка әйберләр салалар).*

**Егет:** Табакка да май булды,
Хуҗа яхшы бай булды,
Яз килергә җай булды,
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Бергә**: Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!
*(Чакыралар).*
Нәүрүзбикә-ә-ә-әү! Нәүрүзбикә-ә-ә-ү-ү-ү!!!

*Бик ерактан Нәүрүзбикә күренә: бизәлгән атта чәчәк булып киенгән кыз балалар арасына килә. Өстендә яшел күлмәк, башында чәчәк такыя, кулында яшел таяк. Җәяү дә килергә мөмкин. Алдан кызлар- егетләр киемендә яшьләр «нәүрүз» әйтеп киләләр. Мөмкинлек булганда, милли коралларда уйнап килү яхшы.*

**Яшьләр**: Ни әйтерсең үзләрен,
Сайрап тора сүзләрен,
Былбыл дию үзләрен,
Нәүрүз мөбарәкбад.

Мәгънә бардыр сүзләрдә,
Әйтик белеп сезләргә,
Бәйрәм килде безләргә,
Нәүрүз мөбарәкбад!

Сайрамаган, кош булмас,
Кошларга һич иш булмас,
Болар кебек һич булмас,
Нәүрүз мөбарәкбад.

Көн йөгердек, белмәдек,
Төн йөгердек, тынмадык,
Сезгә килеп җырладык:
Без Нәүрүзне зурладык.

Агымсулар кичтек без,
Сезгә килеп җиттек без,
Нәүрүз әйтеп үттек без,
Нәүрүз мөбарәкбад.

Җырлап килдек сезләргә,
Әйтсәгез лә безләргә,

Хәер-дога сезләрдә,
Нәүрүз мөбарәкбад.

Бу көн безгә бик тансык,
Сырхауларга сез табиб,
Сезгә килдек, танып без,
Нәүрүз мөбарәкбад.

*Килеп туктыйлар. Егет белән Кыз кулларын күкрәкләренә куеп сәламлиләр.*

**Бар халык бергә:** Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Нәүрүзбикә:** Ач ишегең, керәбез,
Хәер-дога кылабыз,
Аш-сый көтеп торабыз.
*(Аш тутырган табакны бирәләр).*
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә!
*(Табакны янында озата килүчегә тоттыра).*

Мине сагынып көтеп алганыгыз өчен рәхмәт сезгә. Мин үзем дә бу бәйрәмне түземсезлек белән көттем. Кешеләр Язны каршыларга әзерме дип кайгырдым. Болай бәйрәм итәсез икән, димәк, сезнең кәефегез яхшы, сабаннарыгыз кырга чыгарга әзер. Минем чәчәкле аланнарымны, хуш исле кырларымны сагынганыгыз өчен тагын бер кат рәхмәт сезгә!

*(Ике бала йөгереп чыга).*

**Беренче бала**: Нәүрүзбикә!
Кая киттең?

**Нәүрүзбикә**: Сезгә килдем урам буйлап,
Хуҗалардан аш-су юллап.

**Икенче бала:** Нәүрүз, Нәүрүз,
Моңарчы кайда идең?

**Нәүрүзбикә:** Ялан-кырда идем,
Инде сезгә килдем.

**Беренче бала:** Нәүрүз, Нәүрүз, ашыкма, китмә,
Иш бабайны күрми үтмә.

**Нәүрүзбикә**: Бик күп йөрдек илләрдә,
Инде килдек сезләргә.
Иш бабай мич башыннан
Төшсен безнең каршыга.

**Беренче бала:** И Иш бабай, Иш бабай,
Мич башыннан төш, бабай.
Бер тиен акча бир, бабай,
Хуш киләсең, Нәүрүзбикә.

**Икенче бала:** И Иш бабай, Иш бабай,

Мич башыннан төш, бабай.
Бер тиен бирсәң, аз булыр,
Ике тиен бирсәң, күп булыр,
Хуш киләсең, Нәүрүзбикә!
*(Тубал тотып, Иш бабай керә).*

**Иш бабай:** Мал-туарыбыз артсын,
Колыннарыбыз чапсын,
Игеннәребез уңсын,
Күкәй кебек тук булсын!
*(Нәүрүзбикәнең табагына йомырка сала).*

**Нәүрүзбикә:** Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнеңюш булсын,
Оча торган кош булсын!
*(Иш бабай бөртекләрне тубалында җилгәрә, җиргә дә сибеп җибәрә).*

**Иш бабай:** Җир атасы – Җирән сакал,
Җир анасы – Асылбикә,
Ашлыкларга туклыгың бир,
Тамырына ныклыгың бир!
*(Кешеләр: «Амин, амин!» – диешәләр).*

**Иш бабай**: Эш эшләсәң җай белән,
Икмәк булыр май белән,
Кешеләргә бигрәк тә
Иш бабагыз теләктә.
Ашлыгыбыз мул булсын,
Келәтләребез тулсын,
Хуш киләсең, Нәүрүзбикә!
*(Бию номеры башкарыла).*

**Беренче шәкерт:** Казанга бармак кирәк,
Балыкка кармак кирәк,
Шәкерткә акча кирәк,
Нәүрүзбикә түргә уз!
Ачуланма безләргә,
Әйтик чынын сезләргә,
Без килдек кыз күзләргә,
Котлы булсын яз.

**Икенче шәкерт:** Кызларыгыз күп икән,
Кияүләре юк икән,
Безгә бирсе хуп икән,
Нәүрүз мөбарәкбад!
Йөрмәс идек, мал булса,
Матуррак яр булса,
Урлар идек җай булса,
Нәүрүз мөбарәкбад!

**Беренче шәкерт:** Сабый кызның ястыгы юк,
Шәкертләрнең азыгы юк,
Бер үпкәннең языгы юк,
Котлы булсын яз!
**Нәүрүзбикә:** Челтерәп чишмә ага,
Астында комы кала,
Егетләр кызсыз кала,
Теләгегез чын булсын!
**Икенче шәкерт:** Без әйткәнне күрегез,
Чибәр икән үзегез,
Яхшы икән сүзегез,
Нәүрүз мөбарәкбад!
*(Шундагы бер кешегә килеп):*
Бар булса да кызыгыз,
Юк булса да кызыгыз,
Ни булса да түзегез,
Нәүрүз мөбарәкбад!
**Беренче шәкерт**: Абзый, кызың бар икән,
Гөлләр белән пар икән,
Безгә дигән яр икән.
Нәүрүз мөбарәкбад!
**Абзый**: Бездә кызның гүзәле,
Кая егет бүләге?
*(Егет бүләк бирә я бүләкне күрсәтә).*
Килсә иде теләге,
Нәүрүз мөбарәкбад.
Минем кызым мең алтын,
Бирсәң ярар биш алтын,
Карама ялтын-ялтын,
Нәүрүз мөбарәкбад!
Нәүрүз әйткән мин булсам,
Хәер бирсәң син булсаң,
Савапларга юш булсаң,
Нәүрүз мөбарәкбад!
**Нәүрүзбикәнең дуслары аңарга:**
Бүген синең малың бар,
Безгә бирер хәлең бар,
Бирмәең ни хәлең бар,
Нәүрүз мөбарәкбад!
*(Егет китергән бүләкләрнең бер өлешен бирә).*
*(Уртага тагын берәү чыга).*
Кемнең бар бирәчәге,
Әллә кайчан, кичәге,

Кичердем дип уйлагыз,
Коймак белән сыйлагыз.
Үпкәләткән булсам да,
Бер-бер хата кылсам да,
Кичерегез барын да,
Калдырмагыз яренгә.
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Бергә**: Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Нәүрүзбикә**. Ай-һай матур кызлар күп!
Күңелләре мәрҗән күк,
Теле татлы бал булсын,
Егетләр кыздан уңсын,
Юш килсен теләгегез!

**Яшьләр**:Бардыр сезнең маегыз,
Яки бардыр малыгыз,
Бал-май булыр улыгыз,
Мал-май булыр кызыгыз,
Шуны теләп, табакка
Барын бергә куеңыз.

*(Китергән әйберләрен табакка сала).*

**Егетләр**. Гашыйк булдык безләр дә,
Үзебез тик кызларга,
Инде сынап карыйк,
Табышмак әйтеп карыйк.

**Арадан берсе**: Ак юрганга тузан кунды,
Бөтен җире кара булды,
Әхмәди карт кызы юды,
Яшел чәчәк сырып куйды. (*Җавап: кыш үтеп, яз килү).*

**Бер кыз** (җавап әйтә). Егет сүзгә оста икән,
Буе гына кыска икән.
Табышмакка җавап итеп,
Без табышмак әйтеп үтик:
Ак сыерың торып китте,
Кара сыер ятып калды.

**Егет**. Горур гына атлап китте,
Аяк асты шарт-шорт итте.
Дерелдәгән күл өстенә
Елтыр пәрдә каплап китте.

**Кыз**. Сине, егет, тун кидертте,
Такыр башыңны идерде.
Бишмәтеңнең ертыгыннан
Сине салкыны көйдерде, –

Булды сезгә безнең җавап.
**Егетләр**. Алма татлы бал белән,
Егет йөрсә яр белән.
Безгә булсын бу ярлар,
Хуш киләсең, Нәүрүзбикә!
*(Алдар йөгереп керә).*
**Алдар**. Җә-мә-га-а-а-ать!
**Кешеләр**. Ни булды?!
**Алдар**. Безнең кояшка ут капкан!
**Кешеләр**. И, синең шул булыр инде.
**Алдар**. Ел буе алдаганнарым өчен сездән гафу үтенергә килдем. Бурычларымны барыгыздан да кичерәм.
**Кешеләр**. Нинди бурыч? Кемгә биргәнең бар?
**Алдар**. Ел буе бурычка алдап торган идем. Инде мине алдамасагыз да була дим.
**Кешеләр** (көлешәләр). Кичерүен кичердек тә, ди. Аннан нәрсә? Нәүрүзбикәгә теләгең шул гынамы? Ел буе алдаган өчен бу бик аз бит!
**Алдар**. Минем теләк шул инде: Яңа елда тагын да катырак алдый алырга язсын. Менә шуның өчен йомырка китердем. *(Нәүрүзбикәгә йомырка бирә. Нәүрүзбикә ялгыш төшереп җибәрә. Эче буш йомырка икән. Алдар ялганы тотылганын күреп чыгып кача).*
**Нәүрүзбикә**. Алдаганга Алдарны
Гаепләмә сезләр дә.
Килдек бәйрәм итәргә,
Без килмәдек сүзләргә.
Килмәдек үпкә саклап,
Килдек көчсезне яклап.
Түли алган бурычын
Бүген монда түләсен.
Кемнекедер кайтмаса,
Өмет итеп йөрмәсен.
**Кыз**. Дөрес сөйли Нәүрүзбикә,
Бу теләккә нәрсә җитә!
*(Егет белән бергә)*
Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!
**Бөтенесе**. Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!
*(Кыш килеп керә).*
**Кыш**. Биек тауның башында
Озын җирнең межасы.
Үзе белән сөйләшми,
Сез куасыз хуҗасын.
Ак ат җиктем сатуга,

Суда бозлар катуга,
*(Нәүрүзбикәгә карап)*
Ак ат иярләдеңме,
Тайлар йөгәнләдеңме?
Булмаса, китеп тор син!

**Нәүрүзбикә**. Ефәк баулы ак атың
Бардыр синең иледә,
Ефәк баулы күк атым
Бардыр минем илемдә.
Чаптар атым чаптырып,
Чынлап сиңа килгәнмен,
Син боз булсаң,
Мин – күмер.
Көт тә тор эрегәнең!
Җиңелергә килмәдем!
Бирешергә килмәдем,
Көт тә тор җиңелгәнең!

*(Нәүрүзбикәне озатып килүчеләр: «Нәүрүз» көенә җырлап тора).*

Кыш яз белән орышты,
Коңгырт күзен багышты.
Тотышты да егышты,
Җиңәр өчен тырышты.

*(Кыш һәм Яз бу вакытта тартышып, көч сынашып карыйлар, берсе дә җиңә алмый).*

Җәй кыш белән карышты,
Үткен угын корышты,
Йөрәк тотып күреште,
Ук белән үтереште.
Салкын килеп кабышты,
Котлы язга тибеште,
Карлар җиргә ябышты,
Тәннәр туңып бәреште.

*Бу вакытта Салкын, Кар образларына киенгән уенчылар да Кыш яклы булып тартышып карыйлар. Чәчәк киемендәге кызлар Җәйгә ярдәмгә килә. Берсе дә җиңми.*

Килде исеп усал җил,
Буран кебек көчле ул,
Халык тора дерелдәп,
Болыт йөри гөрелдәп.

*Кара болыт, Усал җил дә килеп Кыш ягына басалар.*

Орды болыт башкайларын,
Агып төште сачкайлары,
Халык калды аптырап
Һәрнәрсәтора гөрелдәп.

*Шау-гөр килеп тартышалар. Берсе дә җиңелмәгәч, җибәрәләр.*

**Кыш**. Миндә ирләр көчәер,
Авырулар савыгыр,
Өметләре кабыныр.
Бөтен карлар кышын явар,
Кырда ашлык шуңа уңар,
Яман көчләр миндә тынар,
Син килүгә уяныррлар.

**Яз** (Нәүрүзбикәгә). Миндә яңгыр чәчелер,
Терлек-чәчәк чишенер,
Энҗе кабы ачылыр,
Чыннан хуш ич йөгерешер.

**Кыш**. Үрмәкүчләр, чебеннәр,
Озынборын, еланнар,
Меңәрләшеп йөгерешер,
Меңәрләшеп туарлар.

**Яз**. Синнән тәннәр дерелди,
Миндә тынар карлыгач,
Татлы җырлар сандугач,
Берсен-берсе табышыр.

**Кыш**. Болыт туар гөрелдәп,
Яңгыр явар дерелдәп,
Игеннәрне агызыр,
Яздан файда шул булыр.

**Яз**. Кош-хайваннар терелер,
Бары бергә җыелыр,
Көтү булып коелыр,
Өннәреннән дөньяга.

**Кыш**. Көяр кыры, агачлар,
Уттай янар бар нәрсә,
Кибәр елга, күлләрең, –
Шул булыр, син – Яз килсәң!

**Яз**. Бөтен чәчәк тезелер,
Миндә генә язылыр,
Бөреләре бәйләнеп,
Бер-берсенә сузылыр.

**Кыш**. Беткән булыр икмәгең,
Эссе булыр чикмәнең,
Киялмәссең итегең,
Тишек булыр читегең.

**Яз**. Икмәк бетсә, үстерәм,
Эссе булса, җил өрәм.
Читекләре тишеккә

Яшел чирәм җиткерәм.
**Кыш** *(ырым әйтә)*. Төтәс-төтәс Нәүрүздән,
Чибәр кыз, матур кыздан,
Коңгырт күздән,
Усал күздән
Сакла, Салкыным!
Тфү-тфү, бетсен, китсен!
Тфү-тфү, бетсен, китсен!
Җитмеш агач башына,
Азганга, тузганга,
Җилгә очкан яфрактай,
Очсын-китсен, үтсен-бетсен!
Тфү-тфү, тфү-тфү!
**Нәүрүзбикә**. Безнең уйлар туганда,
Март белән май булганда,
Ак аргамак суйганда,
Синең үз көнең калмас!
**Кыш**. Ай астыннан үткәндә,
Алтын быргы тартканда,
Көн астыннан үткәндә,
Көмеш быргы тартканда,
Синнән генә курыкмам.
**Нәүрүзбикә**. Кыш салкыны тегеләй кит,
Безнең кояш болай кил,
Яшел җәйне җәйләп кил,
Безнең кояш җәһәт кил!
*(Кояш килеп керә).*
**Кояш**. Көннең йөзе булганга,
Көлә-көлә киләм мин,
Салкын кышны эретүнең
Бөтен серен беләм мин.
Җитмеш мичнең җылысы
Минем кадәр җылытмас,
Тик үзе ялкын булган
Ул җылыдан курыкмас.
*(Кыш курка-курка артка чигенә. Нәүрүзбикә килеп аның кулыннан тота).*
**Нәүрүзбикә**. Җир, Җир, көчем бир,
Алты атым көчен бир.
(*Ике яктан да килеп тартыша башлыйлар).*
**Кыш**. Салкынымның зәхмәте,
Яшел язга кагылсын,
Аяклары тотмыйча,
Тигез җирдә абынсын!
*(Нәүрүзбикә ягы җиңә. Яшьләр бергәләп «Нәүрүз» әйтә).*

**Егет белән Кыз**. Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!
Теләгебез уң булсын,
Игеннәр күкрәп уңсын,
Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!

*Бау тартышу, көрәш, йөгереш һәм башка ярышлар башлана. Егетләр-кызлар җырлы уеннар башлый. Бәйрәм шулай дәвам итә. Нәүрүзбикә һәрчак уртада.*

Сценарий авторы – Рифа Харрасова[2]
*Для детей дошкольного возраста*

[2] Харрасова Р. Бәйрәмнәр, туйлар өчен / Ред. Сәүбәнова С. – Казан, 1999. – Б. 56-67.

## Праздник «Навруз» [3]

(для детей старших групп)

В наше время большое значение отводится формированию национальных ценностей путем приобщения дошкольников к народной культуре своего края. В федеральных государственных требованиях выделен региональный компонент, включающий изучение истории, культуры, традиции, искусство своего народа и выступающим средством в формирования в детях чувства любви к малой родине.

В детском саду эта задача может быть решена введением занятий по обучению детей татарскому, русскому языку, проводя татарские и русские национальные праздники, развлечения. Народные подвижные игры включаются в совместную деятельность педагогов специалистов и детей. Интеграция позволяет объединить усилия разных специалистов для решения поставленной цели и взаимопроникновение их в деятельность друг друга при решении задач по воспитанию детей. Каждый специалист решает свою часть задач, используя свои методы, что позволяет не дублировать друг друга и избегать перегрузки детей.

Совместно с педагогами – специалистами разработали проект по ознакомлению с татарской национальной культурой, итогом которого стал праздник-развлечение «Праздник Навруз».

**Цель:** приобщение детей к национальной культуре татарского народа; воспитание любви и уважения к татарскому языку и татарской культуре; ознакомление детей с татарской литературой, фольклором, татарской музыкой и песнями; развитие ловкости и смелости.

Предварительная работа:

- Знакомство с татарским фольклором, традициями, праздниками; прослушивание народных мелодий;
- рассматривание иллюстраций народных костюмов;
- прослушивание и разучивание напевок и народных песен;
- знакомство с танцевальными движениями;
- игра в народные игры;
- подбор костюмов и материала, оформление музыкального зала для проведения мероприятия.

Оборудование (инвентарь): яркие татарские народные костюмы (их элементы) для детей и взрослых, костюмы Шурале, скворцов, весны и зайцев, канат, мешки, обручи, шишки, корзины, угощения.

**Ведущая:** Исәнмесез, кунаклар! Сезне матур бәйрәмгә, Нәүрүз бәйрәменә чакырабыз.

**Ведущая:** Здравствуйте, дорогие гости. Мы вас приглашаем вместе с нами встретить праздник Навруз.

**Ведущий:** Праздник радостный встречаем

[3] Подготовили: Мубаракшина С. В., воспитатель по обучению татарскому языку МАДОУ № 166 совместно с инструктором по физкультуре Андерсен С.В.

Мы в республике родной.
Поздравляем, поздравляем
Всех с Наврузом и весной.

**Ведущий**: В гости к нам Навруз пришел
Всем нам стало хорошо.
Мы танцуем и поем
Дружно весело живем.

*(В зал входят дети, выполняют танцевальные движения)*

**Ребенок:** Нәүрүз килә, Нәүрүз
Бу тәмле сүз
Яз дигән сүз
Яшьлек дигән сүз

**Все:** Нәүрүз килә, Нәүрүз!

**Ребенок:**Снег последний сметает и тает
Рвы водою полны до краев.
Отступает зима, отступает
Истекают мгновенья её.

**Ребенок:** С днем Навруз!
С днем весны!
Мы поздравить к вам пришли.

**Все:** Ас-саляму алейкум!
Навруз – это праздник дружбы!
Навруз – это праздник гостеприимства!
Навруз – это праздник миролюбия!
Навруз – это праздник милосердия.

**Ведущая:** Сколько песен на земле
Все они – тебе и мне.
Будет шире круг друзей
Льется песня веселей.

**Ведущая:** Жылы җил сирпеп үтте
Агачларны селкетте
Уяныгыз, уян тизрәк,
Яз килә, килә.

*Жыр «Яз килә». Забегают дети в костюмах скворцов. (4 мальчика)*

**1 скворец:** Исәнмесез!

**Ведущая:** Исәнмесез, сыерчыклар!

**1 скворец:** Бездә хәбәр!!!

**2 скворец:** У нас новости!

*Звучит музыка, скворцы танцуют, подлетают к воспитателю и улетают.*

**Ведущая:** Мне сейчас скворцы нащебетали, что злой Шурале не пускает на наш праздник Наврузбику.

*Звучит музыка, появляется Шурале, на веревке тащит Наврузбику.*

**Шурале:** Ишь, что удумали. Весну встречать, а я тоже праздник хочу, чтобы было красиво. Будешь жить у меня в лесу, и у меня будет праздник!
**Наврузбика:** Юк, юк, Шурале, мне нельзя жить в неволе. Люблю всем дарить тепло и радость. Отпусти.
**Шурале***(хитро):* И меня любишь?
**Наврузбика:** И тебя тоже, пусти меня к детям, пусть у них будет праздник.
**Шурале:** Нет, не пущу. Я тоже праздника хочу.
*Шурале и Наврузбика уходят*
**Ведущая:** Как же быть??? Надо идти, Наврузбику выручать.
Эй, вставай, честный народ, за весною мы пойдем.
В хоровод вас свой зовем!
*Песня, хоровод: «Әйлән-бәйлән»*
(после песни дети садятся).
*Выходят зайцы.*
**Зайчики:** Исәнмесез, балалар!
**Дети:** Исәнмесез!
**Зайчики:** Сез кая барасыз?
**Ведущая:** Исәнмесез,куяннар. Мы идем в лес, ищем Наврузбику. Помогите нам, покажите дорогу. *(зайцы шепчутся)*
**Зайцы:** Поможем, поможем.
**1 заяц:** Сначала поиграйте с нами в игру «Шишкобол»
*Игра «Шишкобол».*
**2 заяц:** Вот туда идите. Сау булыгыз!
*(Под татарскую народную мелодию выходят девочки в национальных костюмах и исполняют танец с шарфами)*
**Ведущая:** Исәнмесез!
**Дети:** Исәнмесез!
**Ведущая:** Сез кем?
**Девочки:** Без матур кызлар.
**Ведущая:** Вы не встречали Наврузбику?
**1 ребенок:** Её от нас Шурале прячет.
*Заходит Шурале*
**Шурале:** Бу нәрсә? Что за шум?
**Ведущая:** Исәнме, Шүрәле!
**Шүрәле:** Сәлам!
**Ведущая:** Верни нам, Шурале, Наврузбику. Солнце в окно стучится, весну пора встречать.
**Шурале:** Хазер! Не дождетесь! У вас весело, а я буду один грустить… нет уж!
**Ведущая:** Давай с нами дружить.
**Шурале:** Вот ещё, с вами тоже скучно. Вы только и знаете бояться и реветь.
**Ведущая:** Нет, нет, Шурале, тебе с нами понравиться.
*Игра «Чума үрдәк, чума каз»*
**Ведущая:** Нравиться?

**Шурале:** Да так себе. А что, это всё, что вы умеете?
**Ведущая:** Нет. Вот ещё что умеем: красиво петь.
*Исполняется песня «Бир кулыңны»*
**Шурале:** Так и я петь могу, у меня тоже голос ууу ааа. А вот играть вы умеете?
*Игра «Забор», «Бег в мешках» (последний играет Шурале).*
**Шурале:** Дайте я тоже поиграю, очень веселая игра.
*(Шурале залезает в мешок, воспитатель завязывает мешок)*
**Шурале:** Ой, ой, ой. Опять обманули. Отпустите!
**Ведущая:** Нет, не отпустим. Ты зачем Наврузбику не отпускаешь? Без неё весна не наступит.
**Шурале:** Отпустите, а я Наврузбику отпущу. Честно, честно.
**Ведущая:** Что, отпустим его, дети?
**Дети:** Да!
*Развязывают мешок*
**Шурале:** Рәхмәт сезгә, балалар! Я сейчас, я быстро!
*За руку приводит Наврузбику*
**Ведущая:** Көннәр аяз, күктән алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы
Сагынып көткән яз килә!
*Песня: «Нәүрүзбикә һәм яз җыры»*
(музыкально-танцевальная композиция «Пробуждение природы»)
Ведущая: А теперь детвора, поиграть пришла пора.
Музыкальная игра «Тюбетейка»
**Наврузбика:** А сейчас, дети, я поспешу
На поля и луга
Тепло я лесу
Чтоб стояли хлеба.
Зеленела листва
Расцветала родная земля!
**Шурале:** И мне в лес пора. Но я буду вас навещать . и вы меня не забывайте.
**Герои:** Сау булыгыз!
**Ребенок:** Весеннее солнце
Не прячься, свети.
Пришла к нам весна
Татарстан наш, цвети!
**Ребенок:** Азат та син, гүзәл дә син
Әй, туган җирем!
Күкрәп яшә, Татарстан
Республикам минем!
*Исполняется песня «Яшә син туган илем!»*

**Хуш киләсең, Нәүрүз![4]**

(Язны каршылау бәйрәме)

**Максат**:

**1.** Балаларны ел фасылларының матурлыгын күрергә, яз билгеләре турында сөйләргә, табигатьтәге үзгәрешләрне аңлата белергә өйрәтү эшен дәвам итү.

**2**. Диалогик сөйләмне камилләштерү һәм өйрәнелгән грамматик конструкцияләрне сөйләмдә активлаштыру.

**3.** Татар милли бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләргә, традицияләргә кызыксыну уяту.

**4**. Тирә-юньгә, кошларга, хайваннарга карата игътибарлы булу, сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлау:** матур итеп бизәлгән сәхнә. Түрдә, каеннар арасында, Яз кызы – Нәүрүз рәсеме. Сул яктарак айлы Сөембикә манарасы силуэты. Ян пәрдәләрнең бер ягында – Кояш, икенче ягында – Ай сүрәте. Кояш ягыннан пәрдәләр – чәчәкләр, ай куелган ягы йолдызлар белән бизәлгән. Сәхнә түрендә «Хуш киләсең, Нәүрүз!» дигән сүзләр язылган. Идәндә – зур вазада каеннар «кара каргалар» кабартылган шарлар куелган. Музыка яңгырый, әкренәя. Сәхнәгә алып баручы чыга.

**Алып баручы:**

Хөрмәтле әти-әниләр, кадерле кунаклар, балалар! Без бүген бирегә, язны Нәүрүзбикәне каршы алу бәйрәменә җыелдык. Бәйрәмдә халкыбызның дәртле җырларын, жырлы биюле уеннарын күрерсез, үзегез дә рәхәтләнеп биерсез.

Бәйрәм тамашасына рәхим итегез!

Без сезгә саулык-сәламәтлек, бәхет, уңышлар телибез. Барлык өметләрегез дә чынга ашсын!

Язгы яңа ел котлы булсын!

Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Җыр «Бәйрәм җыры»** (Ф. Сафин көе, Р. Корбан сүзләре)

**1 нче бала.** Әйдә, кояш, син нурыңны
Кызганма бер дә,
Зур бәйрәм, күңелле бәйрәм
Нәүрүз бүген бездә.

**2 нче бала.** Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!
Куяннар туңып беткәндер
Иссен җылы җил.

[4] Түбән Кама татар теле тәрбиячеләре Ганеева А., Мингазова Р.Р.

**3 нче бала.** Тизрәк кил безгә җылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!
Чыпчыкларга җырлар өйрәт
Уйна, сайра, көл.

**4нче бала.** Чәчәкләр белән күмелсен
Без яшәгән ил,
Тизрәк кил безгә җылы яз
Тизрәк-тизрәк кил!

**Җыр «Яз җитә»** (Җ. Фәйзи көе, Ф. Кәрим сүзләре)

**Алып баручы:**

Әй, малалайлар, кызлар, әйдәгез, Нәүрүзбикә килгәнче, өйдән-өйгә йөреп, Нәүрүз әйтик, сый-хөрмәт җыйыйк.

***Музыка.***

*Сәхнәгә бер төркем балалар керә. Кулларында чиләкләр, анда йомыркалар, бүләкләр.*

**1 нче бала.** Ач ишегең керәбез.
Нәүрүз әйтеп киләбез.
Хәер-дога кылабыз,
Аш-сый көтеп торабыз,
Нәүрүз мөбарәк булсын.

**2 нче бала**. Аягым җиңел булсын,
Яңа ел котлы булсын,
Ашлыгыгыз мул булсын,
Башагы биш карыш булсын
Нәүрүз мөбарәк булсын!!!

**Түтәй:** Керегез кер балакайларым, без сезне күптәннән көтәбез инде. Нәүрүз котлы булсын!

**3 нче бала.** Мал туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын.
Игеннәрегез уңсын –
Чыгарыгыз бүләкләр.
Нәүрүз котлы булсын!

**Түтәй:** Мәгез - мәгез балалар!
Нәүрүз котлы булсын! *(бүләкләр тарата чыгып китәләр)*

*Балалар музыка астында сәхнәгә килеп керәләр.*

**Алып баручы:** Балалар күрсәтегез әле күпме җыйдыгыз. У-у-у күп булган, булдыргансыз. Әйдәгез әле барыбыз да аны шушы табака салыйк (берәм-берәм китереп салалар).

Алъяпкычың чигүле,
Үзең чиккән түгелме?
Җырлап –биеп, уйнап көлеп
Күтәрик күңелне.

***Уен «Кулъяулыгым»***

**Алып баручы**: Без - без, без идек
Без бер рәткә тезелдек,
Биибез дә җырлыйбыз,
Бер дә оялып тормыйбыз.

Балалар, Нәүрүз килсә генә яз була бит. Әйдәгез, яз гүзәле Нәүрүзбикәне чакырабыз.

**Балалар:** Кил, Нәүрүз, кил тизрәк!

***Шау гөр килеп Нәүрүз керә, чәчәкләр керә.***

**Нәүрүзбикә:** Әссаләмәгаләйкем, кадерле дуслар.
Агым сулар кичтем мин,
Сезгә килеп җиттем мин,
Нәүрүз әйтеп үттек без,
Нәүрүз мөбәрәк булсын

Мине сагынып көтеп, алганыгыз өчен бик зур рәхмәт сезгә!

***Концерт номерлары.***

1. Г. Тукайның «Карак песи» шигыре укыла.
2. Кызлар биюе «Чәчәкләр».

***Кар бөртекләрен ияртеп, Кыш бабай килеп керә.***

**Кыш бабай:** Бу нинди тавыш монда, кем әле минем биләмәләремә баш булмакчы?

**Алып баручы:** Кыш бабай юкка ачуланасың. Синең көннәрең үтеп бара бит инде. Биләмәләреңне язга Нәүрүзбикәгә тапшырырга вакыт җитте. Кара әле тәрәзәгә, гөрләп шаулап яз килә!

**Кыш бабай**: Туктагыз әле, үзе белән сөйләшәм. (Нәүрүзбикә каршысына басып).

Миңа әйтми килгәнсең,
Кышны җиңәм дигәнсең,
Ха-ха-ха
Бер өрермен җил исәр,
Шыткан чәчәкне кисәр,
Ике өрсәм - кар ятар,
Елга күлгә боз катар,
Кит, Нәүрүз, кит!

**Нәүрүзбикә:** Шып - дисәм җилең тынар
Елмайсам- карың елар
Үзең кит кыш!

**Кыш бабай**: Кар яу, яу, яу
Нәүрүздән яса зур тау!
***(кар бөртекләре биюе)***
Юк-юк, мин китмим. Тартышмыйча гына язга — Нәүрүзбикәгә биләмәләремне бирү юк.
**Нәүрүзбикә:** Синең бөтен шартыңа да күнәм мин.
**Кыш бабай:** 1 нче шартым.
Менә кашык, менә күкәй,
Тот кулыңа чибәркәй.
Син дә йөгер мин дә калмам.
Кем узар бу ярышта.
***Нәүрүзбикә беренче булып килә.***
**Кыш бабай:** Әйдә хәзер биюдә ярышабыз (бииләр, Кыш бабай егыла).
**Кыш бабай:** Уф арыдым, сусадым
Харап булдым җиңелдем.
Эредем бит эредем.
Бетте, барсы да бетте,
Актык сәгатем сукты.
Сау булыгыз дусларым,
Хушыгыз күз нурларым.
Шатланыгыз, көлегез, уйнагыз,
Сау булыгыз!!!
***Вальс уйнала. Кыш бабай чыгып китә.***
**Алып баручы:** Салкын кышны яз җиңде
Моны барчагыз күрде.
Кулны кулга тотынышып
Бәйрәм итик көн буе…
**Җыр «Яз килгән»** (Н. Яхина көе һәм сүзләре)
**Нәүрүзбикә:**
Котлап сәлам бирдегез
Мине көтеп алдыгыз.
Тук булсын малларыгыз
Мул булсын балларыгыз.
***Балалар белән «Чума үрдәк, чума каз» уенын уйнау.***
**«Тамчылар»** җыры (Н. Лотфуллина көе һәм сүзләре)
**Алып баручы:**
Хөрмәтле дуслар! Бәйрәм тамашасы ахырына якынлашты. Әллә нинди авыр елларда да үз йөзен югалтмыйча, әнә шулай шат күңелле, сау рухлы булып калган ул безнең халык. Мәңге шулай зирәк акыллы булсын, имин яшәсен!

Бүгенгенең гүзәл мизгелләре
Күңелләрдә калсын уелып
Тагын шулай дуслар бергәләшеп,
Очрашырга язсын җыелып.

*Балалар бакчалары өчен*

**Нәүрүз бәйрәме: яз килә – «Нәүрүз килә»**[5]
(зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен)

**Максат:** Татар халкының милли бәйрәме «Нәүрүз» бәйрәме турында балаларның белемнәрен киңәйтү. Милли горурлык хисләре тәрбияләү.
**Бурычлар:**
- бәйрәмдә катнашасы килү теләге булдыру, иптәшләренең чыгышларын дикъкать белән карарга һәм тыңларга өйрәтү;
- бәйрәм мөхите булдыру, балаларда күтәренке кәеф тудыру;
- матур әдәбият һәм фольклор әсәрләрен сәнгатьле итеп башкарырга өйрәтү.

**Җиһазлар:** уеннар өчен кирәк- яраклар, кулъяулык, ачкыч. кәрзин күчтәнәчләр, бүләкләр.
**Алдан әзерлек эше:** Җырлар, шигырьләр, мәкальләр өйрәнү. Әти-әниләрне, әби- бабайларны кунакка чакыру.
**Бәйрәм барышы:** зал язгы табигатьне чагылдырып бизәлгән: ясалма агачлар, чәчәкләр, кояш. Плакат эленгән: «Яз шатлыгы күңелегезгә күчсен. Бәйрәмегез якты, матур булсын».
**Алып баручы:** Хәерле көн, балалар, кунаклар. Сезнең барыгызны да язгы зур бәйрәм – Нәүрүз бәйрәме белән котлыйбыз. Бу бәйрәмне безгә борынгы бабаларыбыз биреп калдырган. Кешеләр бу бәйрәмне кыш үтеп, табигать яңара башлагач, көннең төн белән тигезләшкән мәлендә билгеләп үткәннәр. Нәүрүз иң шатлыклы яз бәйрәме- өмет бәйрәме булып безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Таң ату белән кешеләр учак кабызганнар, аш-су пешереп бер-берсен сыйлаганнар, төрле уеннар, ярышлар уздырганнар. Без дә бүген уйнап, җырлап ярышып Нәүрүзбикәне каршы алырбыз.
**1 бала:** Әйдә, кояш, сип нурыңны,
Кызганма бер дә,
Зур бәйрәм, күңелле бәйрәм
Яз бүген бездә.
**2 бала:** Тизрәк кил безгә, жылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!
Куяннар туныл беткәндер,
Иссен җылы җил.

---
[5] Югары категорияле татар теле тәрбиячесе Галиева А.Г., югары категорияле музыка җитәкчесе Кутбеева Ю.Р.

**3 бала:** Урманда бит җылы өй дә,
Җылы мич тә юк.
Куяннарның әбиләре
Бәйләми оек.
**4бала:** Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!
Кошчыкларга җырлар өйрәт,
Уйна, сайра, көл.
**5 бала:**Урманда бит пешермиләр
Түгәрәк калач.
Песнәкләрнең туннары юк,
Тамаклары ач.
**6 бала:** Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!
Балыкларны коткар берүк,-
Боз астында күл.
**7 бала:**Чәчәкләр белән күмелсен
Без яшәгән ил.
Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!

**Җыр «Яз килә»**

***(Убырлы карчык керә.***
***Җеп белән урап бәйләнгән Нәүрүзбикәне алып килә)***

**Убырлы карчык:** Килми генә торсын әле яз! Менә Нәүрүзбикәне алып китеп үземнең өемә бикләп куям. Миңа да бәйрәм кирәк. Минем өемә яз китерсен, матурлык китерсен!

**Нәүрүзбикә:** Юк – юк, җибәр мине, Убырлы, мин бикләнеп яши алмыйм. Мин кешеләрне бик, бик яратам. Балаларга яз китерәсем, шатлык өләшәсем бар.

**Убырлы карчык:** Ә – ә – ә, балаларны яратасың, ә мине яратмыйсыңмы?

**Нәүрүзбикә:** Әйбәт булсаң, явызлыклар кылмасаң, сине дә яратырмын, сиңа да җылы, якты, кояшлы көннәр алып килермен.

**Убырлы карчык:** Җылы, якты, кояшлы көннәр алып килерсеңме? Андый рәхәтлекләрне башкалар белән бүлешеп булмый инде. Әйдә, үземә генә алып килерсең андый көннәрне. Менә мин сине шушы ачкыч белән өемдә бикләп тотармын *(ачкыч күрсәтә)*. Кулъяулыгыма яхшылап төенләп куйыйм әле *(ачкычны кулъяулыкка төенләп, кесәсенә салганда төенле кулъяулык төшеп кала. Убырлы Нәүрүзбикәне алып чыгып китә)*.

**Алып баручы:** Балалар, нишлибез инде? Нәүрүзбикәдән башка язда килми, кояш та чыкмый бит. *(Аптырап йөргәндә төенләнгән кулъяулыкны табып ала. Чишеп ачкычын алмакчы була, чишелми. Кулъяулык сөйләшә).*

**Кулъяулык** *(аудио язма):* Юк, мин гади яулык түгел, бик тиз генә чишелмим. Мине чишәсегез килсә, җырлап – биеп, уйнап көлеп күңелемне күрегез. Шартымны үтәсәгез, бәлки чишелермен – ачкычлы булырсыз.

**Алып баручы:** Кулъяулыкның да шарты бар икән, Убырлы карчыкныкы шул ул! Балалар, без бу шартны үти алабыз бит. Әйдәгез әле, уйнап җырлап, биеп алыйк!

1. **Уен «Капкалы»**

(чишеп карый, чишелми)

2. **Җыр «Яз килә»**

(чишеп карый, чишелми)

3. **Шигырләр сөйләү**

(чишеп карый, чишелми)

4. **Аерым җыр «Солдатлар»**

(чишеп карый, чишелми)

**Алып баручы: Балалар, чишелми бит әле бу яулык һаман, Нишләргә инде!? Т**атар халкы элек-электән укымышлы, зыялы халык булган, мәкальләр, әйтемнәр уйлап чыгарган. Әллә без дә мәкалләр әйтеп карыйкмы икән?

5. **Барлык балалар белән уен: «Төенләнгән кулъяулык»**

*(мәкальнең башын алып баручы әйтә, азагын кулъяулык бирелгән бала әйтеп бетерә).*

**Алып баручы:** *(уен беткәч)* Әйдәгез инде кулъяулыкның төенен чишеп карыйк *(яулык чишелә ачкычны алалар).*

*(Убырлы карчык керә)*

**Убырлы карчык:** Кая югалттым соң шул кулъяулыгымны? Сез күрмәдегезме?

**Алып баручы:** Күрдек тә, таптык та, инде. Ачкычны да кулга төшердек. Менә! *(Күрсәтә)*

**Убырлы карчык:** Минем ачкыч бит ул, бирегез!

**Алып баручы:** Бирми генә торыйк әле. Менә безнең балалар белән ярышып кара, җиңә алсаң, карап – карарбыз.

**Ярышлар:**

1. **«Кашыкка күкәй куеп узышу» (Убырлы җиңелә)**
2. **«Капчык киеп узышу».**

*(Соңгы уенда Убырлы да катнаша, ул капчыкка кергәч, капчык авызын бәйләп куялар. Ул кычкыра, чыгаруларын таләп итә).*

**Алып баручы:** Менә, Убырлы карчык эләктердек үзеңне! Нәүрүзбикәне азат итсәң, без дә сине коткарырбыз. Риза булмасаң, чыгармыйбыз.

**Убырлы карчык:** *(еламсырап)* коткарыгыз гына, җибәрәм Нәүрүзбикәне.Үз кулларым белән китереп бирермен.

**Алып баручы:** Ышанып җибәрәбезме, балалар? (Әйе). Ярый инде, бар чык. Алып кил Нәүрүзбикәне. (Чыгара, ачкычны бирә. Убырлы чыгып Нәүрүзбикәне алып керә).

**Убырлы карчык:** Менә алып килдем- сүземдә тордым *(үзе китә).*

**Нәүрүзбикә:** Рәхмәт, сез мине явыз карчыктан коткардыгыз.

Агымсулар кичтем мин,
Биектаулар үттем мин.
Сезне сагынып килдем мин-
Нәүрүз котлы булсын

**Алып баручы:** Балалар, Нәүрүзбикәне уртага алып аңа матур җырыбызны җырлыйк әле. Килегез!

**Җыр «Нәүрүз белән балалар җыры»**

**Нәүрүзбикә:** Рәхмәт, балалар, матур җырыгыз өчен. Мин дә буш килмәдем- сезгә язгы матур, җылы көннәр, сихәтле яңгырлар алып килдем. Язгы кояш һәр көнегезне шатлыкка, бәхеткә күмсен. Менә бусы- сезгә бәйрәм күчтәнәче, рәхәтләнеп сыйланыгыз!

Сыерчык сайрап үтте.
Һавалар зыңлап китте.
Шатлатланып каршы алыгыз,
Яз җитте бит, яз җитте!

*(Күчтәнәчләр салынган кәрзинне бирә. Балалар рәхмәт әйтеп алалар)*

***Бәйрәм тәмам***

## Навруз – праздник весны

(для детей старшей группы)

**Цель:** Приобщить детей к татарской национальной культуре, воздействием различных средств музыкальной деятельности. Знакомить с татарским национальным фольклором, праздником – Навруз, с помощью татарских стихов, песен, танцев и народных игр. Привлекать к активному участию в веселом празднике.

**Предварительная работа:** Слушание татарских народных песен и мелодий,

Разучивание песен, стихов на татарском языке. Разучивание танцев и хороводов. Тематическая беседа по сказкам Г. Тукая. Изготовление тюльпанов.

**Оборудование:** Музыкальный центр. Мультимедиа экран, слайды. Ёлочки, деревья, солнце, ласточки, весенние цветы. (Оформление зала в виде лесной поляны.) Разные атрибуты к играм: тюльпаны, гребень, деревянные ложки, муляжи яйца, мешки.

**ХОД ПРАЗДНИКА:**

**Ведущий:** Исәнмесез, балалар һәм кунаклар! Здравствуйте, ребята и гости! Мы сегодня собрались на татарский народный праздник Навруз. Навруз отмечался в день весеннего равноденствия 21-22 марта. В этот день встречали весну.

Ребята, что означает слово Нәүрүз? Нәүрүз – по восточному календарю, означает «яңа көн»-«новый день». В этот день люди веселились от души, радовались приходу весны, готовили угощения, ходили в гости, забывали друг другу обиды, просили прощения, желали хозяевам в новом году здоровья, долголетия и богатый урожай.

Нәүрүз сүзенең мәгънәсе фарсыча яңа көн дигәнне аңлата. Бу көнне өйдән-өйгә кереп, теләк теләп, бүләк җыеп йөргәннәр. Йорт хуҗаларына яңа елда саулык-иминлек, кырларга бай уңыш, озын гомер теләгәннәр. Нәүрүз ул-игелек, дуслык бәйрәме. Бу гузәл, язгы матур бәйрәм көнендә кешелә бер-берсенә кунакка йөриләр, бер берләренә булган үпкәләрен оныталар, бер –берсен гафу итәләр.

Ул бәйрәмдә яз кызы гүзәл Нәүрүзбикә белән Кыш бабай төрлечә көч сынашалар. Биюдә, җырда, төрле уеннарда гел Нәүрүзбикә җинеп чыга.

Когда приходит к нам Навруз,
Цветут сады, цветут поля.
Когда приходит к нам Навруз,
Весною дышет вся земля!
Когда приходит к нам Навруз,
Звучит и музыка, и смех.

Поздравления принимаем и сами
Поздравляем всех!
Нәүрүз бәйрәме котлы булсын,
Эче тулы нур булсын!
Нәүрәз көен кем көйләсә,
Ул дәртле һәм бай булсын!
Нәүрүз, Нәүрүз, зур рәхмәт
Телибез изге, теләк.
Бәйрәм мөбарак булсын!

А сейчас дети прочитают нам стихи о большом празднике Навруз, о встрече весны.

**<u>1 ребёнок</u>**:
Пробудилось все ото сна,
В гости к нам пришла весна!

**<u>2 ребёнок</u>**:
И Навруз на целый год.
Пусть вам счастье принесет.

**<u>3 ребёнок</u>**:
Новый день, как новый год,
Радость всем нам принесет!

**<u>4 ребёнок</u>**:
Весна шагает по полям.
В лучах тепла и света.
Сегодня Навруз у нас,
И нам приятно это!

**<u>5 ребёнок</u>**:
Яз килә! Яз килә!
Сыерчыклар килә,
Гөрләшеп, сайрашып,
Җырчы кошлар килә.

**<u>6 ребёнок</u>**:
Яз килә. Кояш
Елмаеп тора
Урман яңгыратып,
Кәккүк кычкыра:
Күк-кү, күк – кү.

**<u>7 ребёнок</u>**:
Яз килде, кояш көлде
Дөньяга нур бөркелде.
Уянды бар агачлар,
Куанды алмагачлар.

**<u>Ведущая:</u>**
Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,

Нәүрүзне зурлыйк әле.
Гөрләвекләр тавышына кушылып
Җырлыйк әле.
- А сейчас дети исполнят песню «Кил син, язым».

**Песня «Кил син, язым» («Приходи весна скорей»)**

*(слова Р. Валеевой, перевод Е. Муравьева, музыка Л. Батыр-Булгари)*

1. Тып-тын һава, нурлар ява,
Көн аяз.
Бар дөньяга нурлар сибеп.
Киләяз.
**Кушымта:** Кил син, язым, тизрәк кил,
Бик сагынып көтәбез.
Җырлар җырлап, сөеп, зурлап,
Сине тәбрик итәрбез!
2. Ашыгабыз сине тизрә
Күрергә.
Ящь үләннән ялан тәпи
Йөрергә.
**Кушымта:**
3. Кил син тизрәк, бөтен дөнья
Уянсын.
Сайрар кошлар, күбәләкләр
Куансын.
**Кушымта:**

1. Дружно мы весну встречаем
После вьюг.
Солнце ярко освещает
Все вокруг.
**Припев:** Приходи весна, скорей,
Землю солнышком согрей
Чтобы птицы звонко пели,
Чтобы стало веселей.
2. Распускаются деревья
И цветы.
По траве зеленой бегать
Будем мы.
**Припев:**
3. Скоро птицы издалека
Прилетят.
Защебечут свои песни
Для ребят.
**Припев:**

**<u>Ведущая:</u>**
От забот зима устала. И ура!
Весна настала. Снег под солнцем растопился,
В ручейки он превратился.
Бежит, течёт, поёт вода вместе с ней идёт весна!
**Просмотр презентации про весну – «Навруз».**
**<u>Ведущая:</u>**
Как хорошо и красиво стало кругом. Степь проснулась от зимнего сна и подарит нам яркие и красивые тюльпаны. А значит, пришел на нашу Землю Навруз – праздник добра, счастья, радости. Символом этого праздника является цветок-тюльпан.
(Ведущая показывает тюльпаны и кладёт их на полянку. Под музыку
в зал забегает Водяная – Су анасы и забирает тюльпаны).

**Ведущая:** - Ой, ребятки! Наши тюльпаны забрали. Ты почему наши цветы забрала. Ты кто такая?
**Су анасы:** Я водяная – Су анасы. А кто написал мою сказку.
**Дети:** Габдулла Тукай.
**Ведущая:** Правильно. 26 апреля Г. Тукаю исполняется 130 лет со дня рождения. Нам известны такие сказки как «Шурале», «Су анасы», «Кәҗә белән сарык». Су анасы, отдай нам пожалуйста тюльпаны, без них наш праздник не продолжится.
**Су анасы:** Я потеряла золотой гребень. Помогите мне, пожалуйста найти его, тогда верну тюльпаны.
**Ведущая:** Давайте, ребятки поможем найти золотой гребень. Посмотрите, может он где-то лежит (все дети смотрят, ищут золотой гребень).
**Ведущая**: Вот он нашли. Вот тебе золотой гребень. Отдай нам тюльпаны.
**Су анасы:** Отгадайте сначала мои загадки, а потом отдам тюльпаны.
- Где я живу? (в воде)
- Как по-татарски будет весна? (яз)
- Назовите три месяца весны. (март, апрель, май)
- Когда праздник Навруз отмечают? (21 марта)
- Что означает слово Навруз? (яңа көн – новый день)
- Молодцы! Отгадали. Вот вам тюльпаны.

**Ведущая:** Наш праздник продолжается.
Проснулись ручейки, Запели птицы. И на наш праздник прилетели птицы. Давайте их покормим.
**Девочки исполняют «Танец птичек»**
«Вальс» муз. С. Сайдашева.
(После танца птички подбегают к ведущей шепчут ей на ушко)
**Ведущая:** Птицы нам принесли весточку о том, что к нам идёт сама Навруз. Давайте её позовём.
(дети зовут Навруз. Под музыку появляется Навруз .)
**Навруз:** Исәнмесез, балалар һәм кунаклар. Мин яз кызы – Нәүрүзбикә.
Сезне бәйрәм белән котлыйм. Нәүрүз мөбәрәк булсын !
Хуш, киләсең Нәүрүз .
Разливайся веселье, словно солнца яркий свет.
Здравствуй, праздник наш весенний,
С Наврузом всех, всех, всех!
**Ведущая:** Ребятки, давайте Навруз подарим весенний хоровод.

**Дети исполняют песню «Бәйрәм бүген»**
**(«Приходи весна скорей»)**
*(слова Габдуллы Тукая, музыка Җәүдәт Файзи)*

1. Бар күңеллелек бөтен дөньяда,
Бар бер ямь бүген!
Нәрсәдән бу? Мин беләм: бәйрәм
Бүген, бәйрәм бүген!

2. Яр башында тыңладым мин,
Бер суның дулкынмарын;
Сөйләшәләр үзара: «Бәйрәм бүген,
Бәйрәм бүген!…»
3. Тыңладым әкрен генә искәндә,
Бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын:
«Бәйрәм бүген, Бәйрәм бүген!…»
**Навруз:** Молодцы, ребята! Здорово умеете веселиться. Несла я вам к празднику подарки и очень торопилась. Второпях заблудилась. Заблудившись, не заметила, как потеряла мешок с угощеньями.
**Ведущий:** А, большой мешок?
**Навруз:** Большой, тяжелый! Эх, жаль мне подарков!
**Ведущий:** Ребята, давайте поищем мешок! Может, он где-нибудь недалеко лежит. Посмотрите, может под вашими лавочками он лежит?
*Дети наклоняются, поворачиваются в поисках мешка.*
**Выходит батыр (Ребенок)**
**Батыр:** Смотрите, смотрите! Вот он! Под кустом лежит!
*Батыр быстро подходит к мешку.*
**Батыр:** Вот хорошо, что мешок нашелся! Сейчас мы его развяжем!
**Ведущий:** Ой, не надо!
**Батыр:** Почему?
**Ведущий:** Этот мешок какой-то странный. Сам собой шевелится.
**Мешок начинает шевелиться и подпрыгивать, пугая детей.**
**Батыр:** И, правда! Что-то странное случилось с этим мешком. Только его все равно развязать надо: двум смертям не бывать, а одной-не миновать!
*Развязывает мешок. Из мешка выскакивает Шурале из татарских поверий.*
**Батыр:** Это что еще такое? Что за чудище лесное?
**Шурале:** Чудище? Сам ты чудище-батырище! А я-Шурале! Самый хитрый, самый ловкий, самый красивый! (Достает зеркальце в деревянной оправе и любуется на себя. Затем с обидой обращается к присутствующим.) А вы меня не узнали! На праздник не позвали! Обидели хорошего Шурале! За это и я вам весь праздник испорчу! Подарки ваши я уже припрятал. В заветное местечко. А сейчас начну детей щекотать! Они ни в одну игру не смогут сыграть! (Бегает мимо детей, изображает, что хочет схватить их.)
**Батыр:** Ишь ты, разошелся! А ну отдавай подарки подобру-поздорову, а не то плохо тебе будет!
**Шурале:** Мне плохо? Хи-хи-хи! Хо-хо-хо! Хе-хе-хе! Да я самый умный, самый хитрый, самый сильный Шурале!
**Батыр** *(передразнивая Шурале)*: Ха-ха-ха! Хе-хе-хе! Самый сильный Шурале (Меняет интонацию на угрожающую.) Хватит тут попусту хвастаться! Давай лучше силами померяемся! В честном поединке. А ребята нас судить будут по правде и сами решат, кто здесь самый сильный и ловкий.

*Ведущий подает Батыру канат. Батыр кидает один конец Шурале, и они начинают перетягивать канат. Батыр явно одерживает верх, но не торопится закончить состязание-мотает Шурале на конце каната из стороны в сторону.*
*Шурале вскрикивает.*
**Шурале:** Ай, держите! Улетаю! Ой, спасите! Пропадаю!
*Наконец Батыр выпускает канат из рук, и Шурале плюхается на землю.*
**Ведущий:** Дети, кто победил?
**Дети:** Батыр!
**Ведущий:** Кто на празднике самый сильный?
**Дети:** Батыр!
**Ведущий:** А ты, Шурале, просто хвастун!
**Шурале** *(плачущим голосом)*: Как же так? Я думал, что самый сильный! А Батыр меня победил! Зато я самый умный!
**Батыр:** Опять хвастаешься? Я тебе задам! (Делает шаг в сторону Шурале.)
**Шурале:** Ой, не буду, не буду! Уж вы меня простите, к себе на праздник возьмите! Буду вместе с вами спортом заниматься! И угощенье ваше я вам сейчас отдам. Я его вон там припрятал. *(Вздыхает)*. Хотел сам все съесть, да, видно, не выйдет!
**Ведущий:** Оставим Шурале на празднике?
**Дети:** Да!
**Ведущий:** Веселись и танцуй, мы встречаем Навруз. Мы знаем, что Навруз приходит в день весеннего равноденствия, Когда день и ночь равны. Давайте поиграем в игру «День и ночь».
**Проводится игра «День и ночь».**

**Ведущая:** Вам понравилось играть? А теперь давайте поиграем в татарские национальные игры.
**1. игра: «Капка» (Ворота).**
**2. игра-эстафета: «Перенеси яйцо в ложке».**
**3. игра-эстафета: «Бег в мешках»**
**4. Любимая игра Г. Тукая: «Ачык авыз».**
**Ведущая:** Вот и наступила долгожданная весна. Навруз остаётся вместе с нами. Она нас будет каждый день встречать на улице с тёплым солнышком.
**Навруз:** А теперь пришло время раздать вкусный гостинец. Мин алып килдем сезгә тәмле күчтәнәч. Безнен бәйрәм тәмам. На этом наш праздник закончен. Удачи всем. До свидания. Саубулыгыз.

**Нәүрүз килә, Нәүрүз!**

Ул, әлбәттә, кыр-яланнарда, су буйларында, тау итәкләрендә, табигать кочагында үткәрелә. Балалар өчен «Нәүрүз»не дә зал-сәхнә бәйрәме төсендә, ләкин аны җиргә – табигатькә бәйләнешен ачардай хыял-фантазия белән баетып-бизәп эшләү зарур. Бәйрәмдә Ил агасы, Илбикә, Иш бабай, Тау иясе, Субашы һәм балалар катнаша. Бәйрәм башланыр алдыннан радиодан чакырулы шигырь яңгырый.

Нәүрүз килә, Нәүрүз!
Бу тәмле сүз.
Җир йөзендә тоташ бер ямь ул.
Җир-табигать белән кеше җанын
Игез-тигез иткән бәйрәм ул.

Нәүрүз килә, Нәүрүз!
Бу татлы сүз.
Яз дигән сүз, яшьлек дигән сүз.
Тирәбездә бөтен тереклекне
Шул бәйрәмгә дәшик дигән сүз.
Мөбарәкбад Нәүрүз!
Кил, түргә уз!

Яңарыштан дөнья шатлансын,
Асылына кайтсын рухларыбыз,
Халкыбызның җаны сафлансын.
*Бер бала чәчәк тотып керә, үзе шат.*

**Бала**. Нәүрүз юлга чыккан бит,
Умырзая шыткан бит.

**Укучылар**. Әйе, әйе. Умырзаялар чыккан,
Яз җиткән, яз җиткән!

*«Умырзая» җыры. Әхмәт Фәйзи сүзләре.Умырзаялар (кызлар) биюе башкарыла.*

**Илбикә**. Мең рәхмәт, гөлкәйләрем,
Булды күңелкәйләрем.
Җыр-биюсез ямьлемени
Язның гомеркәйләре.

**Ил агасы**. Сүзең хактыр, Илбикә,
Җыр-биюгә ни җитә.
Безнең халык эшендә дә
Матур көйне иш итә.
Тиздән кырга чыгасы,
Буразналар сузасы.

Язгы эшләр турында
Ни дияр Кыр хуҗасы?
**Иш бабай**. Сабаннар үтсә актарып
Басулар җәйрәп ята.
Ипигә ягып ашарлык
Кара җир безнең якта.
Шул җирдә яшел хәтфәдәй
Уңышлар үссен өчен,
Тып-тыгыз орлыклар тулып
Башаклар пешсен өчен.
Егетләр менә әйтегез,
Язын нишләргә кирәк?
**Егетләр**. Язның көне ел туйдырырлык
Итеп эшләргә кирәк!
**Иш бабай**. Бик дөрес. Иң элек чәчүлеккә җирне эшкәртеп, чәчүлеккә орлыкны әзерләп кую фарыз. Я, орлыкларыгызга күз салыйк әле. Ни чәчсәң, шуны урырсың, диләр. Сез ни чәчмәк буласыз?
*(Малайлар тубалларын күрсәтәләр. Анда манган кукәйләр, сумсалар, вак бәлешләр, кумәчләр, прәннекләр булырга мөмкин).*

Әйе, егетләр, мондый орлыктан әйбәт уңышка өмет тотып була. Инде изге кыр эшләренә тотынганчы көчне төрле ярышларда да сынап-үлчәп карый торган гадәт бар иде без яшь чакта. Сездә ничек?
*(Төрле уеннар, спорт ярышлары башлана).*
Менә Нәүрүзбикә керә.
**Илбикә**. Хуш киләсең, Нәүрүз, хуш киләсең,
Кышлар буе көттек үзеңне.
Оланнарга инде ач йөзеңне,
Һәм ирештер татлы сүзеңне.
**Нәүрүз**. Мин үзем дә сезне сагынып килдем,
Теләкләрем ихлас күңелдән.
Юлыгызга якты бәхет юрап,
Яз гөлләре булып сибелгән.
Яр буенда әнә, ут чәчәкләр –
Учлап кояш сипкән шикелле.
Алар минем сезне сагынуымнан
Шытып чыккан гөлләр бит инде.
*(Җырлы-биюле уен).*
Килдем сезгә игелекләр теләп,
Күгегездә якты нур булсын.
Туфрагыгыз уңыш бирсен күпләп,
Юлдашыгыз яхшы җыр булсын!
*(Нәүрүз җыры башкарыла).*
**Илбикә**. Рәхмәт, Нәүрүз, изге теләгеңә. Балалар Нәүрүз көннәрендә шулай уйнап,

жырлап йөрсеннәр.
*Балаларның күмәк уены башкарыла.(«Роза – гөлнең чәчәге», «Наза», «Бөрлегән» һ.б. булырга мөмкин). Уен бетүгә бер малай йөгереп килә.*
**Малай**. Сез уйныйсыз, жырлыйсыз,
Әйләнәсез, биисез.
Ә урамда кошлар туңа,
Алар хәлен белмисез.
**Алып баручы**. Дөрестән дә без аларны
Искә төшерик әле.
Халык йоласын кайтарыйк,
Ботка пешерик әле.
*Алып баручы кулына казан тотып һәр кешедән әйберләр җыеп чыга. Бер кырыйга казан асыла, учак ягыла.*
**Алып баручы**. Һай, егетләр, кызлар, малайлар,
Апа, абый, әби, бабайлар!
Ботка пеште, ботка бүләбез,
Авыз итми кала күрмәгез!
*(Җыелышып ботка ашыйлар).*
**Ил агасы**. Оланнар! Инде казан төбендә калганын каргаларга бирегез, аш булсын. Кош-кортлар да җиребезгә иминлек, көнебезгә матурлык, халкыбызга татулык, күңелебезгә игелек, өебезгә иминлек, тормышыбызга ныклык, тамагыбызга туклык, аңыбызга аклык, зиһенебезгә зирәклек, нигезебезгә тернәклек, тәнебезгә азатлык, рухыбызга азатлык теләп торсын. Амин.
**Нәүрүз**. Кызлар! Быел мин сезгә электән калган бер бик матур серле уен алып килдем. Уйныйбызмы?
**Кызлар**. Нинди уен соң ул?
**Нәүрүз**. «Яшерәм яулык» дигән уен. Менә сез түгәрәкләнеп утырасыз. Башта җирәбә салып, чират бүлешәбез. Беренче чыккан кыз яулык яшерә. Артына яшергән яулыкны тапкан кеше җәзадан котыла, тапмаганы я сөйгәненең исемен әйтә, я ясак түли.
**Кызлар**. Нинди ясак? Ничек түли.
**Нәүрүз**. Я балдагын, я төймәсен бирә дә, я жырлап, я биеп түләп ала.
**Бер кыз.** Моны бит малайлардан качып уйнаганнар. Анда әйтелгән исемне алар белергә тиеш түгел.
**Нәүрүз**. Шулай, билгеле. Әйдәгез, алардан яшеренеп уйныйбыз.
*Бер читкә китеп утыралар. Әмма бер малай да яулык бөркәнеп, кунак кызы булып аларга ияргә. Шобага салалар, җырлыйлар.*
Урман буйлары абага –
Урман суы шәп ага.
Кем башлап яулык яшерә –
Әйдә, салыйк, шобага.

Яулыкка ия булган кыз:

Яшерәм яулык, яшерәм яулык,
Яшел каен астына.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

Яулыкны ташлый. Икенчесе эзли.

Түгәрәкне өч әйләндем,
Өчләтә өч атладым.
Бигрәк оста яшергәнсең,
Эзләсәм дә тапмадым.

**Кызлар**. Тапмаганның җәзасы:
Я исемен язасың.
Я булмаса, балдагыңны
Ясак түләп аласың.
Кыз Нәүрүзгә бер исем пышылдый.

**Кызлар**. Безгә дә әйт, безгә дә.
*(Кыз бөтенесенең колагына әйтеп чыга, аннан соң үзе яулык яшерә. Чират кунак кызына җитә).*

**Яулыклы малай**. Яшерәм яулык, яшерәм яулык,
Яшереп тормадым әле.
Серен урладым әле. (*Яулыгын салып ата)*.

Һәй, кызлар, инде үзегез миңа ясак түләгез. Юкса, кемнең кемне яратканын бөтен кешегә сөйлим. (*Торып йөгерә, кызлар куа башлыйлар*).

**Нәүрүз**. Борчылмагыз, кызлар. Акылы булса, сер сатып йөрмәс. Инде малайларның үзләрен дә серле уеннарга катнашырга чакырыйк. Бардыр бит берәр шундый уен?

**Кызлар**. Бар, билгеле. Менә «Чума үрдәк, чума каз»ны уйнарга була хәзер. *(Уйныйлар).*

**Нәүрүз**. Я, менә кызларның баягы уенында сер булган күп кенә нәрсә бу уеннарда ачылып та китте бугай. Шулай түгелме? Яшьлекнең яме, тәме шундый уеннарда инде аның. «Һәр язның үз җыры бар», – диләр шагыйрьләр. Чынлап та, быелгы язның да үзенең яңа, матур җырлары тумый калмас. Ә бүгенге бәйрәмне тәмамлар алдыннан, әйдәгез, моннан бик күп язлар элек туып та һаман язлар кебек яшь, матур сакланып яши торган берәр матур җырны искә төшерик әле. Бүгенге бәйрәмнең якты истәлеге булып шул җыр калсын.

*Күмәк җыр яңгырый.*

Сценарий авторы – Клара Булатова[6]

---

[6] ХаррасоваР. Бәйрәмнәр, туйлар өчен / Ред. Сәүбәнова С. – Казан, 1999. – Б.56-67.

Народный праздник «Навруз»
*(для учащихся общеобразовательных школ)*

***Действующие лица:*** *зазывалы (6 человек), дети – Танцоры, Зима, Албасты, Див, Убырлы карчык, Наврузбике****.*** *Под веселую музыку через зал выбегают зазывалы.*

**1. Зазывала:**
К нам, сюда! Собирайся народ!
Сегодня вас много интересного ждет!
Игры, забавы, чудеса из чудес!
Спешите, подарков хватит на всех.

**2. Зазывала:**
Мы зовем к себе тех,
Кто любит танцы, веселье и смех.
Дружно зиму провожай,
Будет летом урожай!

**3. Зазывала:**
Позабавимся на славу!
Веселиться весь народ.
И я думаю удачно
Праздник проводов пройдет!

**4. Зазывала:**
Пожалуйте сюда!
На праздник весны и начала нового года.

**1. Зазывала:**
А теперь, по старинной традиции, пришло время силушкой померяться. А ну, выходи, кто смел, ловок и силен. (*Выходят два батыра*).

**1. Батыр:**
Я здесь самый сильный и ловкий!

**2. Батыр:**
Не правда, это я самый сильный!
*(спорят)*

**2. Зазывала:**
Постойте, а мы сейчас в соревнованиях выясним, кто же на самом деле самый сильный.

**3. Зазывала:**
Состязание первое бег в мешках.*(Бегут, побеждает первый батыр).*

**4. Зазывала:**
Состязание второе бег с ложками.*(Побеждает второй батыр).*

**5. Зазывала:**
Состязание третье, самое главное перетягивание каната. (*Начинают перетягивать и падают в разные стороны).*

**Зазывалы**(*вместе*): Ничья!
(*Батыры обнимаются)*.
**5. Зазывала:**
Но прежде чем весну встречать нужно с почестями Зимушку проводить!
**6. Зазывала:**
Встречайте, в гости к нам идет Зима! (*Под музыку выходит опечаленная Зима)*.
**Зима:**
Спасибо, что пришли меня проводить!
**1 Зазывала:**
Зимушка-Зима!
Что-то ты невесела?
Не ласкают снежны бури?
Что ты часто хмуришь брови?
Здорова ли ты?
**Зима:** Ах!
**2 Зазывала:**
Полно, Зимушка, печалиться.
Ты еще не так стара.
Зима смотрит на себя в зеркало.
**Зима:**
Да, ты прав, не так уж я стара.
Морщины – это ерунда.
**3. Зазывала:**
Ну-ка, встань да приободрись,
По кругу веселей пройдись.
**Зима:**
Ребятушки, а развеселите-ка меня напоследок, да танец мне веселый покажите!
**Зазывалы** (*вместе)*:
С удовольствием! (*татарский танец*).
**4. Зазывала:**
Зимушка, ты пока еще в почете.
Пора подумать об отчете.
**Зима:**
Ну, что ж, начнем отчет.
А проделанной работе
Я всегда веду учет.
**5. Зазывала:**
Снега ты вдоволь потратила на покрывало?
**Зима:**
Немало.
**6. Зазывала:**
Доброй была иль спуску ты всем не давала?

**Зима:**
Бывало.
**1. Зазывала:**
Ну, а теперь мы всех гостей спросим. (*Обращается к зрителям*).
Снега для лыжных прогулок хватало всегда?Да!
**2. Зазывала:**
Скована ль крепко была на озерах вода? Да!
**3. Зазывала:**
Все ли довольны этой зимой, иль не все? Все.
**4. Зазывала:**
Слава Зиме!
**Зима:**
Вот теперь все в полном порядке. Можно и Навруз праздновать. (*Песня на русском).*
**5. Зазывала:**
Навруз это праздник дружбы, так пожелаем людям всей земли мира, дружбы и любви!
**6. Зазывала:**
Навруз это праздник гостеприимства!
**1.Зазывала:**
Навруз – это праздник миролюбия!
**2. Зазывала:**
Навруз – это праздник доброты!
**Зима:**
Желаем всем мира и спокойствия, счастья, успехов, великих свершений! Пусть этот год принесет вам удачу!
**3 .Зазывала:**
Зимушка-зима, согласно обычаю, мы выбрали Наврузбике, она будет символизировать весну на протяжении всего праздника. Наврузбике приготовила для вас сюрприз. Встречайте!
*Слышен звон бубенцов. На машинке (может быть садовая тележка) Албасты и Див везут Убырлы карчык, переодетую в Весну.*
**Зазывалы:** Убырлы карчык! (*Убегают*).
**Албасты, Див:**
Посторонись, поберегись, дай дорогу! Тр-р-р!.. Приехали!
**Албасты:**
Наврузбике приглашали?
**Зима:**
Приглашали.
**Албасты**:
Получите и распишитесь.
**Зима:**
За что расписываться? Наврузбике я не вижу.

**Убырлы карчык:**
Ты что, Зима, Весну-раскрасавицу не признала? Приглашали? Встречайте, как положено! Привет, братушки-ребятушки! Я так торопилась, так торопилась, что слова все по дороге растеряла. (*Албасты*). Ну-ка, поди сюды. Что дальше-то? (*Албасты на ухо ей подсказывает*). А-а-а. Вспомнила. Пора, говорят, к обязанностям своим приступать. Все, Зима, ты можешь быть свободна, мне тут с вами некогда болтать, пора работать, я к этой роли, может, 100 лет готовилась, недоедала, недосыпала.
**Зима:**
Вот ты и проговорилась. Значит, ты Наврузбике ненастоящая.
**Албасты:**
Как это, ненастоящая?
**Див:**
Самая что ни на есть настоящая, и даже справочка имеется. (*Показывают справку).*
**Зима:**
Назначается Весной на весь праздник! Ну и дела!
**Албасты:**
И печать имеется.
**Див:**
И подпись.
**Зима:**
Подпись неразборчива.
**Убырлы карчык:**
Ну, Зима, совсем ты, стара стала, читать, что ль, разучилась?
*Албасты и Див помогают читать.*
**Албасты:**
Подпись самого важного начальника: Шурале.
**Зима:**
Ну, теперь все ясно. Мы тебя на должность Весны принять не сможем.
**Убырлы карчык:**
Как это не можете? Я готовилась, готовилась, никому почти вреда не причинила, разве только чуть-чуть пошалила.
**Зима:**
Да, потому, что Наврузбике просто так не становятся. Это звание заслужить нужно.
**Убырлы карчык:**
О, так это проще простого! Говори, что делать нужно? Для меня это раз плюнуть!
**Зима:**
Во-первых, Наврузбике очень скромная и добрая девочка! Во-вторых, она должна приготовить для гостей угощения. А самое главное, Наврузбике должна быть очень талантливой. Вот есть у тебя хотя бы один талант?

**Албасты:**
О-о, у нашей красавицы полно талантов она умеет прыгать *(дает знак Убырлы карчык, она прыгает)*, бегать, и опять прыгать, и опять бегать, и прыгать.
**Убырлы карчык:** (*запыхавшись*)
Погоди, не могу больше! Уморили!
**Зима:**
Не быть тебе, Убырлы карчык, Наврузбике.
**Убырлы карчык:**
Все равно не уйду, не уйду и весь праздник вам испорчу! (*Албасты и Див что-то шепчут Убырлы карчык).* Точно. Я покину ваш праздник, если выполните мое условие. Загадки наши отгадайте. Вот первая загадка:
Сердитый недотрога
Живет в глуши лесной.
Иголок очень много,
А нитки ни одной. (Ёжик).
Что такое перед нами:
Две оглобли за ушами,
На глазах по колесу,
И сиделка на носу? (Очки).
Два березовых коня
По снегам несут меня,
Кони эти рыжи
И зовут их ... (Лыжи).
Что стоит в конце страницы,
Украшая всю тетрадь?
Чем вы можете гордиться?
Ну, конечно, цифрой... (Пять).
И зелен и густ
На грядке куст.
Покопай немножко
Под кустом ... (Картошка).
Со мной в поход легко идти,
Со мною весело в пути,
И я крикун, и я буян,
Я звонкий, круглый ... (Барабан).
Смело в небе проплывает,
Обгоняя птиц полет,
Человек им управляет
Что такое? ... (Самолет).
Работяга он упорный.
Он родился в шубе черной.
И всю жизнь в земле живет.
Кто же это? Это ... (Крот).

– Ну, надо же, все загадки отгадали. Такую роль доверили, а я не справилась. Может, все же я останусь, все равно настоящей нет, да и какая она – никто не знает.

**Зима:** А вот мы сейчас все и увидим! (*Музыкальная зарисовка).*

**1 Зазывала:**

Наврузбике идет, весне дорогу.
Забудьте зимние тревоги,
Забудьте вьюги и мороз,
Не бойтесь отморозить нос.

**Наврузбике:**

На дворе сосульки плакали,
Под лучами солнца таяли!
Голубые слезы капали,
И проталину оставили!
Звенят сосульки весело,
И поет капель, весенняя
Эта солнечная песенка
С Наврузом поздравление! (Поет песню, на заднем фоне музыкальная зарисовка).

**Зима:**

Ну что же, власть твоя Весна!
Я отдаю тебе свое правленье.
Я служила верно.
И под белой шубой сохранила всходы.
Ты же дай им всходы, оживи природу.
Под музыку Зима начинает удаляться.

**Зазывалы:**

С крыш сосульки зазвенели!
Прощай Зимушка-зима!
Все сердца помолодели!
Прощай Зимушка-зима!
Здравствуй девица Весна!

**Наврузбике:**

С давних времен, люди проращивали зерно на праздник. И сегодня я приготовила каждому гостю подарок горшочек с пророщенным зерном, как символ хорошего урожая. Богатства и здоровья. (*Выбегают танцоры, зазывалы раздают горшочки).*

**Танцоры**:

Прошла Зимушка зима,
Открывайте все дома.
Выходите-ка гулять,
Весну-красну встречать.

**Нәүрүз**

*Укытучы:* Нәүрүз – төрки халыкларның кышны озату, язны каршы алу бәйрәме. Ул 21-22 мартта уза. Бу бәйрәмнәрдә өйдән-өйгә кереп бүләк җыйганнар. Кешеләр теләкләрен Нәүрүзгә әйтеп калырга теләгәннәр. Ярышлар үткәрелгән, уен-җыр булган.

*Укучы:* Тиздән Нәүрүз бәйрәме җитә. Килми дә килми. Урманга барыйм әле, Нәүрүзне алып килим әле.*(Укучы адашкан, елый).*

*Урман хуҗасы:* Кем бар анда, минем урманымда кем елый?

*Укучы*: Бу мин.

*Урман хуҗасы:* Нишләп йөрисең син, кызыкай?

*Укучы:* Тиздән Нәүрүз җитә. Ул үзе юк. Аны эзләргә килгән идем, адаштым. (*Елый*).

*Урман хуҗасы*: Елама, мин сиңа тылсымлы чәчәк бүләк итәм. Ул сиңа Нәүрүзне табарга ярдәм итә.

*Укучы*: Рәхмәт. Минем елыйсым килми. Биисем килә. (*Бииләр*).

*Урман хуҗасы:* Ярый, кызым, хәерле юл сиңа! Мин дә китәм. Урманда яз көне эшләрем күп.

*Аю (йокыдан уяна):* Мине кем уятты. Хәзер мин сине ашыйм (*кызга*).

*Укучы:* Тукта, Аю дус, менә бу чәчәкне иснәп кара әле.

*Аю:* Нинди хуш исле бу чәчәк! Ачуларым бетте инде минем. Мин сиңа бер шигырь сөйлим әле.

Яз килә! Яз килә!
Сыерчыклар килә.
Гөрләшеп, сайрашып,
Җырчы кошлар килә,
Бик күңелле тышта.
Кар эри, боз китә,
Чабышып йөриләр
Малайлар бер читтә.

*Укучы*: Аю, рәхмәт сиңа. (*Аю китә*).

*Бүре:* Ууу, ит тә юк. Ашыйсы килә.

*Укучы*: Туктагыз әле, бүреләр. Иснәгез әле бу чәчәкне.

*Бүреләр:* Җырлыйсы килә. Нинди рәхәт! (*Җырлыйлар*).

(*Куян килә*).

*Укучы:* Куяннар, килегез бирегә.

*Куяннар:* Без бүреләрдән куркабыз (*чәчәк иснилар*). Безнең уйныйсы килә (*курайда уйныйлар*).

*Нәүрүз яшәгән өй янына киләләр, звонок бирәләр.*

*Нәүрүз:* Кем бар анда?

*Укучы:* Бу мин – Алсу. Мин сине бәйрәмгә алырга килдем.

*Нәүрүз*: Хәзер барам.

*Укучы*: Урман җәнлекләрен дә алып барыйк. Алар минем дуслар. (*Җырлыйлар*).
*Нәүрүз*: Әйдәгез, авылга кереп күкәй җыеп чыгыйк.
*Укучы:* Әй, түтәй, бир безгә күкәй,
Безгә бирсәң бер күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй!
*Укучы:* Нәүрүз котлы булсын,
Нәүрүз котлы булсын!
Нәүрүз килә! Нәүрүз, түрдән уз!
*Укучылар:* Күңел ачабыз! Күңел ачабыз! (*Җырлыйлар*).
Сыерчык телеграмма китерә. (*Укыйлар*).
«Тиздән килеп җитәрмен. Кыш бабай».*(Кыш бабай килә).*
*Кыш бабай*: Бу нинди бәйрәм?
*Укучы:* Яз кызы, Нәүрүз килде. Нәүрүз бәйрәме үткәрәбез.
*Кыш бабай*: Ярышыйк әле:
Мин җиңелсәм – китәрмен, җиңсәм – калырмын. Нәүрүз белән чанада ярышабыз.
Кем алда килер – шул кала. (*Кыш бабай җиңелә*).
Биеп ярышалар, Кыш бабай егыла.
*Кыш бабай:* Арыдым, эрим бугай. (*Кыш бабай китә).*
*Нәүрүз:* Бәйрәмне дәвам итәбез. (*Бииләр*).

**Нәүрүз бәйрәме**

*Җиһазлау. Авыл өе макеты.*

*Алып баручы:* Бүген бездә Нәүрүз бәйрәме. Элек татарлар яңа елны 22 мартта каршылаганнар. Аны Нәүрүз бәйрәме дип атаганнар. Бу көнне малайлар һәм кызлар матур киемнәр кигәннәр, аннан соң һәр өйгә кергәннәр, матур җырлар җырлаганнар, биегәннәр. Хуҗаларны бәйрәм белән котлаганнар. *(Балалар өй тәрәзәсе янына киләләр).*

*Балалар:* Ач ишегең, керәбез,
Нәүрүз әйтеп киләбез!
Өйдәме, түтәй? Тизрәк бир күкәй!
Бирсәң безгә өч күкәй, тавыгың салыр йөз күкәй!

*(Хуҗалар тәрәзәдән ярма, күкәй бирәләр*).

*Балалар:*

Нәүрүз котлы булсын!
Нәүрүз котлы булсын!

Алып баручы. Әйдәгез әле, балалар, бергәләп Нәүрүзбикәне чакырыйк.

*Балалар:* Нәүрүзбикә! Нәүрүзбикә!

(Нәүрүзбикә керә).

*Нәүрүзбикә:* Исәнмесез, балалар!
Бик күп сулар үттем мин,
Агымсулар кичтем мин,
Сезгә килеп җиттем мин,
Нәүрүз әйтеп үттем мин,
Нәүрүз мөбарәк булсын!

*1 нче укучы*:
Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде.
Былбылдан аваз килде.
Нәүрүз мөбарәк булсын!

*3 нче укучы*:
Нәүрүз килде, тиз килде,
Нәүрүз килде, яз килде,
Яз белән байлык килде,
Яз белән шатлык килде.

*(«Килде яз» җыры. С.Сәйдәшев көе).*

*Нәүрүзбикә:*
Яратыгыз көзне дә,
Яратыгыз кышны да,
Яратыгыз җәйне дә,
Яратыгыз язны да.

*Балалар*:

Нәүрүз, Нәүрүз, зур рәхмәт!
Нәүрүз, Нәүрүз, зур рәхмәт!

*(Кыңгырау тавышы ишетелә).*

*Алып баручы*: Балалар, ишеттегезме, кыңгырау тавышы. Безгә кунаклар килә, ахрысы.(*Кыш бабай керә).*

*Балалар:* Исәнме, Кыш бабай!

*Кыш бабай:* (*Нәүрүзгә*) Бу нинди бәйрәм монда?

Миңа әйтми киткәнсең,
Ха-ха-ха.
Бер өрсәм, җил исәр,
Ике өрсәм – кар явар,
Кит, Нәүрүз, кит!

*Нәүрүзбикә:*

Шып итсәм – җил туктар,
Елмайсам – карың елар,
Үзең кит, Кыш бабай!

*Кыш бабай:*

Минем җитез атларым бар,
Гыйнвар, февраль айларым бар.

*Нәүрүзбикә:*

Минем дә бит атларым бар,
Җылы, апрель, майларым бар.

*Кыш бабай:*

Әйдә, алайса ярышыйк,
Кем җиңә, шул кала.

*Алып баручы*: Кыш бабай, Нәүрүзбикә, менә күрәсезме, балалар икегезне дә яраталар.

*Кыш бабай*: Рәхмәт, рәхмәт. Менә хәзер карыйк әле ярышып, бераз аркан тартышып.

(*Нәүрүзбикә, Кыш бабай балалар белән 2 командага бүленеп, аркан тартышалар. Нәүрүзбикә командасы җиңә).*

*Кыш бабай*:

Менә кашык, менә күкәй,
Тот кулыңа, чибәркәй.
Син дә йөгер, мин дә калмам,
Кайсыбыз килер алдан?

(*Нәүрүзбикә, Кыш бабай кашыкка күкәй салып йөгерәләр).*

*Алып баручы*: Инде хәзер биеп алабыз.

*(Кыш бабай бии-бии дә, егыла).*

*Кыш бабай*:

Уф арыдым, су кирәк,
Җиңелдем бит, җиңелдем.

Эредем бит, эредем,
Яз хуҗа булды инде!
Сезнең белән Нәүрүз кала,
Ә мин киттем, хушыгыз.

*Алып баручы*: Балалар, әйдәгез, Нәүрүзбикәгә җырлар җырлыйбыз, шигырьләр сөйлибез. (*Яз турында шигырьләр сөйләргә, җырлар җырларга мөмкин.Бәйрәмне йомгаклау.)*.

**Нәүрүз**

Бәйрәм буласы бүлмә кыш, яз күенешләре ясалган рәсемнәр белән бизәлә.
Әкрен генә музыка уйный.

**Алып баручы.**
Исәнмесез, саумысыз, һәрбарчагыз!
Бүген бездә бәйрәм көн.
Уйнап күңел ачам, дип,
Мәктәпкә килде һәркем.

Бүген бездә «Нәүрүз» бәйрәме. Элгәре заманнарда безнең бабаларыбыз, бабаларыбызның бабалары Яңа ел бәйрәмен 22 мартта уздырганнар. Аны «Нәүрүз» дип атаганнар. Бу көнне малайлар һәм кызлар, һәр өйгә кереп, хуҗаларга такмак-такмазалар әйткәннәр, аларны бәйрәм белән котлаганнар.

*(Күңелле көй яңгырый.)*

**Балалар.**
Ач ишегең, керәбез,
Нәүрүз әйтеп киләбез!
Өйдәме, түтәй? Тизрәк бир күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй!

*(Хуҗалар тәрәзәдән ярма, күкәй бирәләр.)*

**Балалар.**
Нәүрүз котлы булсын!
Нәүрүз котлы булсын!

**1 нче укучы.**
Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде.
Былбылдан аваз килде –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**2 нче укучы.**
Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**3 нче укучы.**
Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**4 нче укучы.**
Казанга бармак кирәк,
Балыкка кармак кирәк,
Ә безгә бәйрәм кирәк,

Нәүрүз мөбарәкбад!
**5 нче укучы.**
Нәүрүз әйттек без сезгә,
Хакын бирегез безгә,
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә,
Нәүрүз мөбарәкбад!
**Бергә.**
Нәүрүз мөбарәкбад!
**Алып баручы.**
Нәүрүз бәйрәме мөбарәк булсын,
Яз саен кабатланып торсын!
Котлап сәлам бирдегез,
Әйдәгез, сыйланыгыз! *(Сый өләшә)*
**Алып баручы.** Нәүрүз – Яңа ел, яңа көн дигәнне аңлата. Ул – көн белән төн тигезләшкән вакыт. Менә шуннан соң көн озыная башлый.
Ә Нәүрүз бәйрәме нинди бәйрәм?
**Укучылар.**
- Яңа ел бәйрәме!
- Яз бәйрәме!
- Кышны озату, язны каршылау бәйрәме!
- Дуслык бәйрәме!

*( «Яз җитә» җыры башкарыла. Бүлмәгә «карга костюмы» кигән балалар керә.)*
**Алып баручы.** Балалар, карагыз әле, Кара каргалар килгән, алар – яз киләсен хәбәр итүчеләр.
**Кара каргалар.** Исәнмесез, балалар!
**Алып баручы.** Кая таба очасыз?
**1 нче кара карга.**
Ачылды ак калын юрган,
Исә язгы җилләр дә,
Без кайтабыз сагындырган
Туган, үскән җирләргә.
**2 нче кара карга.**
Көннәрне юлда үткәреп.
Куанышып сезгә очтык,
Канатларга күтәреп,
Сезгә яз алып кайттык.
**1 нче кара карга.**Яз кызы Нәүрүзбикә тиздән сезгә килеп җитә! *(каргалар «очып» чыгып китәләр.)*
**6 нчы укучы.**
Көннәр аяз, күктән алсу
Нур сибеп кояш көлә.

Җиргә тама көмеш тамчы,
Сагынып көткән яз килә!
**7 нче укучы.**
Әйтегезче, кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк!
*(Кошлар сайравы ишетелә. «Кил син, язым» җырының 1 нче куплеты башкарыла. Җыр ахырында «каргалар» белән Яз-Нәүрүзбикә керә)*
**Нәүрүз.**
Исәнмесез, балалар!
Бик күп сулар үттем мин,
Агымсулар кичтем мин,
Сезгәкилеп җиттем мин,
Нәүрүз әйтеп үттем мин.
Нәүрүз мөбарәк булсын!
**8 нче укучы.**
Нәүрүз килде, тиз килде,
Нәүрүз килде, яз килде,
Яз белән байлык килде,
Яз белән шатлык килде.
*( «Кил син, язым» җырының 2,3 нче куплетлары башкарыла.)*
**Нәүрүз.**
Котлап сәлам бирдегез,
Мине көтеп алдыгыз,
Имин йортта торыгыз,
Кәеф-сафа корыгыз.
Инде мине тыңлагыз,
Моңаеп утырмагыз–
Уйнагыз да көлегез,
Биегез дә җырлагыз–
Нәүрүз мөбарәкбад!
**Алып баручы.**
Әй, дуслар, килегез,
Күңел ачу көнебез.
Татарча матур итеп
Без биибез күрегез!
*( «Зәлидә» биюе башкарыла)*
**Алып баручы.**
Яз иртәсен котлагандай матур булып,
Зәңгәр күкне каплап алды зәңгәр болыт.
Бизәкләгән төсле булды бөтен һава,
Кар өстенә шыбыр-шыбыр ләйсән ява!

*( «Ләйсән яңгыр» җыры башкарыла.)*
**Нәүрүз.**
Яратыгыз көзне дә, яратыгыз кышны да,
Яратыгыз җәйне дә, яратыгыз язны да.
**Балалар.**
Нәүрәз, нәүрүз, зур рәхмәт!
Нәүрәз, нәүрүз, зур рәхмәт!
*(Кыңгырау тавышы ишетелә)*
**Алып баручы.**
Балалар, ишеттегезме, кыңгырау тавышы. Безгә кунаклар килә ахрысы.
*(Кыш бабай керә)*
**Балалар.** Исәнме, Кыш бабай!
**Кыш бабай.***(Нәүрүзгә)*
Бу нинди бәйрәм монда?
Миңа әйтми киткәнсең,
Бер өрсәм, җил исәр,
Ике өрсәм – кар явар,
Кит, Нәүрүз, кит!
**Нәүрүз.**
Шып итсәм – җил туктар,
Елмайсам – карыңелар,
Үзең кит, Кыш бабай!
**Кыш бабай:**
Минем җитез атларым бар,
Гыйнвар, февраль айларым бар.
**Нәүрүз.**
Минем дә бит атларым бар,
Җылы апрель айларым бар.
**Кыш бабай.**
Әйдә, алайса ярышыйк,
Кем җиңә, шул кала.
**Алып баручы.** Кыш бабай, Нәүрүзбикә, балалар бит икегезне дә яраталар.
**Кыш бабай.** Рәхмәт, рәхмәт. Менә хәзер карыйк әле ярышып.
Менә кашык, менә күкәй,
Тот кулыңа, чибәркәй.
Син дә йөгер, мин дә калмам,
Кайсыбыз килер алдан?
*(Нәүрүз, Кыш бабай кашыкка күкәй салып йөгерәләр.)*
**Алып баручы.** Инде хәзер биеп алабыз.
*(Кыш бабай бии-бии дә егыла.)*
**Кыш бабай.**
Уф, арыдым, су кирәк,
Җиңелдем бит, җиңелдем.

Эредем бит, эредем,
Яз хуҗа булды инде!
Сезнең белән Нәүрүз кала,
Ә мин киттем, хушыгыз.
*(Саубуллашып китә. Күңелле көй ишетелә. Хуҗа Насретдин керә.)*
**Хуҗа Насретдин.**
Хуҗа Насретдин товары
Һәркемгә дә җитәрлек.
Тары-бары, растабары
Һәркөн сатыла товары.
Яшьләр өчен шатлык мин дә,
Картларга да тансык мин.
Халык үлмәс, мин үлмәсәм.
Мәңге яшә, Насретдин!
**Алып баручы.** Әссәләмәгаләйкүм, Хуҗа Насретдин!
**Хуҗа Насретдин.** Вәгаләйкем әссәлам! Исәнмесез, балалар! Бу базармы?
**Алып баручы.** Юк, бу базар түгел, бу мәктәп.
**Хуҗа Насретдин.** Яхшы, яхшы, миңа мәктәп тә ярый, бераз ял итеп алырмын.
**Алып баручы.**Хуҗа Насретдин! Бүген бездә «Нәүрүз» бәйрәме. Ә сез безнең олыкунагыбыз булырсыз. Сез бит бик күп мәзәк, мәкаль, табышмак, такмаклар беләсез. Безгә дә сөйләмәссезме икән?
**Хуҗа Насретдин.** Була ул, тыңлагыз! Мин мәкальне башлармын, сез тәмамларсыз.
Тырышкан табар ... *(ташка кадак кагар.)*
Кем эшләми ... *(шул ашамый.)*
Ялкау утырып йоклый ... *(ятып ашый.)*
**Хуҗа Насретдин.**
Бүген «Нәүрүз» бәйрәме,
Күңел ачу көнебез.
Тәмле прәннекләр алырга
Минем янга килегез.
Товарымны сатмыйм әле,
Сезне сыйлыйсым килә.
«Нәүрүз» бәйрәмен котлап,
Бүләк бирәсем килә.
Сый-хөрмәтләр сезгә булсын,
Нәүрүз мөбарәк булсын!
**Балалар.** Рәхмәт сезгә, Насретдин!
**Хуҗа Насретдин.** Миңа китәргә кирәк, сау булыгыз, балалар! *(Китә)*
Алып баручы. Әйдәгез әле, балалар, бергәләп җырлап алыйк.*( «Кулчатыр» җыры башкарыла.)*
**9 нчы укучы.**
Җырларыбыз юлдаш булсын,

Юлдаш булсын, яңгырап торсын.
Эшләрегез уңнан булсын,
Илебезне бизәп торсын!
*(Җыр башкарыла.)*
**Нәүрүз.**
Кояш, чык, чык, чык,
Тәти кашык базарда,
Ботка пешәр казанда.
Батыр карны елак ит,
Җылың белән кунак ит.
*(Кояш чыга.)*
**10 нчы укучы.**
Кояш, кояш, син биектә
Бар дөньяны күрәсең.
Әйтче, иң матур җир кайда?
Син бит инде беләсең?!
**Кояш.**
Әйе, беләм, мин әйтәм, тыңлап кара:
Иң матур җир – туган җир ул,
Онытма моны, бала!
**Алып баручы.**
Алдагы көннәрегездә
Телибез зур уңышлар.
Муллыкта, тыныч тормышта
Хезмәт итегез, дуслар![7]
*( «Туган телдә җырыбыз» җыры башкарыла.)*

[7] Мәктәптә бәйрәмнәр, кичәләр. Рус телле балалар өчен дәрестән тыш чаралар җыентыгы. Казан. 1999.; Балалар өчен җырлар. Хәрефле шакмаклар. Луиза Батыр-Болгари.

**Нәүрүз**

**Яшьләр**. Ни әйтерсең үзләрен,
Сайрап тора сүзләрен,
Былбыл дию үзләрен,
Нәүрүз мөбарәкбад.
Мәгънә бардыр сүзләрдә,
Әйтим әле сезгә дә,
Бәйрәм килде безләргә,
Нәүрүз мөбарәкбад!
Сайрамаган, кош булмас,
Кошларга һич иш булмас,
Болар кеби һич булмас,
Нәүрүз мөбарәкбад.
Көн йөгердек, белмәдек,
Төн йөгердек, тынмадык,
Сезгә килеп җырладык:
Без Нәүрүзне зурладык.
Агымсулар кичтек без,
Сезгә килеп җиттек без,
Нәүрүз әйтеп үттек без,
Нәүрүз мөбарәкбад.
Җырлап килдек сезләргә,
Әйтсәгез лә безләргә,
Хәер-дога сезләрдә,
Нәүрүз мөбарәкбад.
*(Килеп туктыйлар. Егет белән Кыз кулларын күкрәкләренә куеп сәламлиләр).*

**Бар халык бергә.** Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Нәүрүзбикә.** Ач ишегең, керәбез,
Хәер-дога кылабыз,
Аш-сый күтеп торабыз.
*(Аш тутырган табакны бирәләр)*
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә!
*(Табакны янында озата килүчегә тоттыра)*

Мине сагынып көтеп алганыгыз өчен рәхмәт сезгә. Мин үзем дә бу бәйрәмне түземсезлек белән көттем. Кешеләр Язны каршыларга әзерме дип кайгырдым. Болай бәйрәм итәсез икән, димәк, сезнең кәефегез яхшы, сабаннарыгыз кырга чыгарга әзер. Минем чәчәкле аланнарымны, хуш исле кырларымны сагынганыгыз өчен тагын бер кат рәхмәт сезгә!

*(Ике бала йөгереп чыга)*

**Беренче бала.** Нәүрүзбикә!

Кая киттең?

**Нәүрүзбикә.** Сезгә килдем урам буйлап,

Хуҗалардан аш-су юллап.

**Икенче бала.** Нәүрүз, Нәүрүз,

Моңарчы кайда идең?

**Нәүрүзбикә.** Ялан-кырда идем,

Инде сезгә килдем.

**Беренче бала.** Нәүрүз, Нәүрүз, ашыкма, китмә,

Иш бабайны күрми үтмә.

**Нәүрүзбикә.** Бик күп йөрдек илләрдә,

Инде килдек сезләргә.

Иш бабай мич башыннан

Төшсен безнең каршыга.

**Беренче бала.** И Иш бабай, Иш бабай,

Мич башыннан төш, бабай.

Бер тиен акча бир, бабай,

Хуш киләсең, Нәүрүзбикә.

**Икенче бала.** И Иш бабай, Иш бабай,

Мич башыннан төш, бабай.

Бер тиен бирсәң, аз булыр,

Ике тиен бирсәң, күп булыр,

Хуш киләсең, Нәүрүзбикә!

Тубал тотып, Иш бабай керә.

Балалар биюе башкарыла.

**Иш бабай.** Мал-туарыбыз артсын,

Колыннарыбыз чапсын,

Игеннәребез уңсын,

Күкәй кебек тук булсын!

*(Нәүрүзбикәнең табагына йомырка сала)*

**Нәүрүзбикә.** Абзый, эшең уң булсын,

Теләгәнең юш булсын,

Оча торган кош булсын!

*(Иш бабай бөртекләрне тубалында җилгәрә, җиргә дә сибеп җибәрә)*

**Иш бабай.** Җир атасы – Җирән сакал,

Җир анасы – Асылбикә,

Ашлыкларга туклыгың бир,

Тамырына ныклыгың бир!

*(Кешеләр: «Амин, амин!» – диешәләр)*

**Иш бабай.** Эш эшләсәң җай белән,

Икмәк булыр май белән,

Кешеләргә бигрәк тә

Иш бабагыз теләктә.
Ашлыгыбыз мул булсын,
Келәтләребез тулсын,
Хуш киләсең, Нәүрүзбикә!
Бию номеры башкарыла.

**Шәкерт.** Казанга бармак кирәк,
Балыкка кармак кирәк,
Шәкерткә акча кирәк,
Нәүрүзбикә түргә уз!
Ачуланма безләргә,
Әйтик чынын сезләргә,
Без килдек кыз күзләргә,
Котлы булсын яз.

**Икенче шәкерт.** Кызларыгыз күп икән,
Кияүләре юк икән,
Безгә берсе хуп икән,
Нәүрүз мөбарәкбад!
Йөрмәс идек, мал булса,
Матуррак яр булса,
Урлар идек җай булса,
Нәүрүз мөбарәкбад!

**Беренче шәкерт.** Сабый кызның ястыгы юк,
Шәкертләрнең азыгы юк,
Бер үпкәннең языгы юк,
Котлы булсын яз!

**Нәүрүзбикә.** Челтерәп чишмә ага,
Астында комы кала,
Егетләр кызсыз кала,
Теләгегез чын булсын!

**Икенче шәкерт.** Без әйткәнне күрегез,
Чибәр икән үзегез,
Яхшы икән сүзегез,
Нәүрүз мөбарәкбад!
*(Шундагы бер кешегә килеп):*
Бар булса да кызыгыз,
Юк булса да кызыгыз,
Ни булса да түзегез,
Нәүрүз мөбарәкбад!

**Беренче шәкерт.** Абзый, кызың бар икән,
Гөлләр белән пар икән,
Безгә дигән яр икән.
Нәүрүз мөбарәкбад!

**Абзый** Бездә кызның гүзәле,
Кая егет бүләге?
*(Егет бүләк бирә я бүләкне күрсәтә)*
Килсә иде теләге,
Нәүрүз мөбарәкбад.
Минем кызым мең алтын,
Бирсәң ярар биш алтын,
Карама ялтын-ялтын,
Нәүрүз мөбарәкбад!
Нәүрүз әйткән мин булсам,
Хәер бирсәң син булсаң,
Савапларга юш булсаң,
Нәүрүз мөбарәкбад!
*(Нәүрүзбикәнең дуслары аңарга)*
Бүген синең малың бар,
Безгә бирер хәлең бар,
Бирмичә ни хәлең бар,
Нәүрүз мөбарәкбад!
*(Егет китергән бүләкләрнең бер өлешен бирә)*
Егетләр биюе.
*(Уртага тагын берәү чыга)*
Кемнең бар бирәчәге,
Әллә кайчан, кичәге,
Кичердем дип уйлагыз,
Коймак белән сыйлагыз.
Үпкәләткән булсам да,
Бер-бер хата кылсам да,
Кичерегез барын да,
Калдырмагыз яренгә.
Нәүрүз мөбарәк булсын!
**Бергә.** Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!
(Картлар биюе)
**Нәүрүзбикә.** Ай-һай матур кызлар күп!
Күңелләре мәрҗән күк,
Теле татлы бал булсын,
Егетләр кыздан уңсын,
Юш килсен теләгегез!
**Яшьләр** *(әнигә карап).*
Бардыр сезнең маегыз,
Яки бардыр малыгыз,
Бал-май булыр улыгыз,

Мал-май булыр кызыгыз,
Шуны теләп, табакка
Барын бергә куегыз.

*(Әни кеше китергән әйберләрен табакка сала)*

**Егетләр.** Гашыйк булдык безләр дә,
Үзебез тик кызларга,
Инде сынап карыйк,
Табышмак әйтеп карыйк.

**Арадан берсе.** Ак юрганга тузан кунды,
Бөтен җире кара булды,
Әхмәди карт кызы юды,
Яшел чәчәк сырып куйды.

*(Җавап: кыш үтеп, яз килү)*

**Бер кыз***(җавап әйтә).* Егет сүзгә оста икән,
Буе гына кыска икән.
Табышмакка җавап итеп,
Без табышмак әйтеп үтик:
Ак сыерың торып китте,
Кара сыер ятып калды.

**Егет.** Горур гына атлап китте,
Аяк асты шарт-шорт итте.
Дерелдәгән күл өстенә
Елтыр пәрдә каплап китте.

**Кыз.**Сиңа тун кидертте,
Такыр башыңны идерде.
Бишмәтеңнең ертыгыннан
Сине салкыны көйдерде. –
Булды сезгә безнең җавап.

**Егетләр.** Алма татлы бал белән,
Егет йөрсә яр белән.
Безгә булсын бу ярлар,
Хуш киләсең, Нәүрүзбикә!

*Алдар йөгереп керә.*

**Алдар.** Җә-мә-га-а-а-ать!

**Кешеләр.** Ни булды?!

**Алдар.** Безнең кояшка ут капкан!

**Кешеләр.** И, синең шул булыр инде.

**Алдар.** Ел буе алдаганнарым өчен сездән гафу үтенергә килдем. Бурычларымны барыгыздан да кичерәм.

**Кешеләр.** Нинди бурыч? Кемгә биргәнең бар?

**Алдар.** Ел буе бурычка алдап торган идем. Инде мине алдамасагыз да була дим.

**Кешеләр***(көлешәләр).* Кичерүен кичердек тә, ди. Аннан нәрсә? Нәүрүзбикәгә теләгең шул гынамы? Ел буе алдаган өчен бу бик аз бит!

**Алдар.** Минем теләк шул инде: Яңа елда тагын да катырак алдый алырга язсын. Менә шуның өчен йомырка китердем. *(Нәүрүзбикәгә йомырка бирә. Нәүрүзбикә ялгыш төшереп җибәрә. Эче буш йомырка икән. Алдар ялганы тотылганыг күреп чыгып кача).*

**Нәүрүзбикә.** Алдаганга Алдарны
Гаепләмә сезләр дә.
Килдек бәйрәм итәргә,
Без килмәдек сүзләргә.
Килмәдек үпкә саклап,
Килдек көчсезне яклап.
Түли алган бурычын
Бүген монда түләсен.
Кемнекедер кайтмаса,
Өмет итеп йөрмәсен.

**Кыз.** Дөрес сөйли Нәүрүзбикә,
Бу теләккә нәрсә җитә!
*(Егет белән бергә)*
Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Бөтенесе.** Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк булсын!
*(Кыш килеп керә)*

**Кыш.** Биек тауның башында
Озын җирнең межасы.
Үзе белән сөйләшми,
Сез куасыз хуҗасын.
Ак ат җиктем сатуга,
Суда бозлар катуга,
*(Нәүрүзбикәгә карап)*
Ак ат иярләдеңме,
Тайлар йөгәнләдеңме?
Булмаса, китеп тор син!

**Нәүрүзбикә.** Ефәк баулы ак атың
Бардыр синең илеңдә,
Ефәк баулы күк атым
Бардыр минем илемдә.
Чаптар атым чаптырып,
Чыңлап сиңа килгәнмен,
Син боз булсаң,
Мин – күмер.
Көт тә тор эрегәнең!
Җиңелергә килмәдем!

Бирешергә килмәдем,
Көт тә тор җиңелгәнең!

*(Нәүрүзбикәне озатып килүчеләр: «Нәүрүз» көенә җырлап тора)*

Кыш яз белән орышты,
Коңгырт күзен багышты.
Тотышты да егышты,
Җиңәр өчен тырышты.

*(Кыш һәм Яз бу вакытта тартышып, көч сынашып карыйлар, берсе дә җиңә алмый)*

Җәй кыш белән карышты,
Үткен угын корышты,
Йөрәк тотып күреште,
Ук белән үтереште.
Салкын килеп кабышты,
Котлы язга тибеште,
Карлар җиргә ябышты,
Тәннәр туңып бәреште.

*Бу вакытта Салкын, Кар образларына киенгән уенчылар да Кыш яклы булып тартышып карыйлар. Чәчәк киемендәге кызлар Җәйгә ярдәмгә килә. Берсе дә җиңми.*

Килде исеп усал җил,
Буран кебек көчле ул,
Халык тора дерелдәп,
Болыт йөри гөрелдәп.

*Кара болыт, Усал җил дә килеп Кыш ягына басалар.*

Орды болыт башкайларын,
Агып төште сачкайлары,
Халык калды аптырап
Һәрни гөрелдәп тора.

*Шау-гөр килеп тартышалар. Берсе дә җиңелмәгәч, җибәрәләр.*

**Кыш.** Миндә ирләр көчәер,
Авырулар савыгыр,
Өметләре кабыныр.
Бөтен карлар кышын явар,
Кырда ашлык шуңа уңар,
Яман көчләр миндә тынар,
Син килүгә уянырлар.

**Яз***(Нәүрүзбикәгә)*. Миндә яңгыр чәчелер,
Терлек-чәчәк чишенер,
Энҗе кабы ачылыр,
Чыннан хуш ис йөгерешер.

**Кыш.** Үрмәкүчләр, чебеннәр,
Озынборын, еланнар,

Меңәрләшеп йөгерешер,
Меңәрләшеп туарлар.

**Яз.** Синнән тәннәр дерелди,
Миндә тынар карлыгач,
Татлы җырлар сандугач,
Берсен-берсе табышыр.

**Кыш.** Болыт туар гөрелдәп,
Яңгыр явар дерелдәп,
Игеннәрне агызыр,
Яздан файда шул булыр.

**Яз.** Кош-хайваннар терелер,
Бары бергә җыелыр,
Көтү булып коелыр,
Өннәреннән дөньяга.

**Кыш.** Көяр кыры, агачлар,
Уттай янар бар нәрсә,
Кибәр елга, күлләрең, –
Шул булыр, син – Яз килсәң!

**Яз.** Бөтен чәчәк тезелер,
Миндә генә язылыр,
Бөреләре бәйләнеп,
Бер-берсенә сузылыр.

**Кыш.** Беткән булыр икмәгең,
Эссе булыр чикмәнең,
Киялмәссең итегең,
Тишек булыр читегең.

**Яз.** Икмәк бетсә, үстерәм,
Эссе булса, җил өрәм.
Читекләре тишеккә
Яшел чирәм җиткерәм.

**Кыш**(*ырым әйтә*). Төтәс-төтәс Нәүрүздән,
Чибәр кыз, матур кыздан,
Коңгырт күздән,
Усал күздән
Сакла, Салкыным!
Тфү-тфү, бетсен, китсен!
Тфү-тфү, бетсен, китсен!
Җитмеш агач башына,
Азганга, тузганга,
Җилгә очкан яфрактай,
Очсын-китсен, үтсен-бетсен!
Тфү-тфү, тфү-тфү!

**Нәүрүзбикә.** Безнең уйлар туганда,
Март белән май булганда,
Ак аргамак суйганда,
Синең үз көнең калмас!
**Кыш.** Ай астыннан үткәндә,
Алтын быргы тартканда,
Көн астыннан үткәндә,
Көмеш быргы тартканда,
Синнән генә курыкмам.
**Нәүрүзбикә.** Кыш салкыны тегеләй кит,
Безнең кояш болай кил,
Яшел җәйне җәйләп кил,
Безнең кояш җәһәт кил!
*(Кояш килеп керә)*
**Кояш.** Көннең йөзе булганга,
Көлә-көлә киләм мин,
Салкын кышны эретүнең
Бөтен серен беләм мин.
Җитмеш мичнең җылысы
Минем кадәр җылытмас,
Тик үзе ялкын булган
Ул җылыдан курыкмас.

Обряд «грачиная каша»
*(внеклассное мероприятие для учащихся младшего и среднего звена)*

**Ведущий:** В назначенный день мальчики и девочки группами обходили дома на своем конце деревни, и собирали продукты для коллективной каши. По «дорожкам», выстроенным полотнами, на поле выбегают дети, они несут продукты для «детской каши» *(мешочки с крупой).*
**Ведущий:** Одна хозяйка даст крупы – пшена, полбы или гречки, другая – яиц, третья – масла. Для каши все сгодится!
*Звучат детские «заклички».*
*(Из книги Р.К. Уразмановой «Обряды и праздники татар Поволжья и Урала»):*

1) Дәр, дәр, дәрәгә,
Иртә торып, бер икенче сөрәнгә.
Сөрән суккан – бай булган.
Хай, хай, хай, диләр,
Гали абзый бай, диләр,
Берәр кашык май, диләр!
(Дарь, дарь, на дарю. Через день – сорэнь. Кто участвует в сорэнь – будет богатым, кто курит – будет бедный. Хай-хай-хай, говорят, дедушка Гали

богатый, говорят, ложку масла дай, говорят).

2) Карга әйтә: карр, карр,
Туем җитте, барр, барр,
Ярма, күкәй алып бар,
Ипи, итен тагы бар,
Барр, барр, барр…
(Ворона говорит: карр, карр, настало мое пиршество, приходи, приходи, крупу, яйца приноси, молоко, масло приноси, хлеба, мяса приноси, приходи, приходи, приходи…)

3) Дәр, дәр, дәрәгә!
Майлы ботка казанда,
Сырлы кашык базарда.
Иртән торып – сөрәнгә,
Берсекөнгә сабанга!
(Дарь, дарь на дарю! Масляная каша в котле, раскрашенная ложка на базаре. Встав утром – на сорэнь, послезавтра – на сабан).

4) Зәр, зәр, зәрәгә,
Иртә торып – боткага,
Берсекөнгә – күкәйгә,
Аннан кала – сөрәнгә.
(Зэр-зэр, на зарю, завтра, встав на кашу, послезавтра – на яйца).
*Дети отдают продукты женщинам, которые варят кашу в большом котле.*
**Ведущий**: На природе, в большом котле из собранных продуктов пожилые женщины готовили для детей кашу.
**Ведущий** *(на татарском языке):*
Болында апалар һәм әбиләр халыктан җыйган азыклардан зур казанда ботка пешергәннәр. Казанда пешкән ботканы саф һавада ашавы нинди тәмле һәм күңелле!
**Ведущий**: Ах, какая вкусная каша из общего котла, да на свежем воздухе!..
**Ведущий:** Этот веселый ритуал – знак начала подготовки к Сабантую.

Методическая разработка классного часа
на тему: «К нам приходит НАВРУЗ»

Тема: К нам приходит Навруз!

**Цели**:

- Познакомить учащихся с праздником Навруз;
- Развивать познавательный интерес и логическое мышление детей;
- Воспитывать чувство гордости за свою страну, воспитывать интерес к народным традициям.

**Оборудование**: Плакат с изображением весны, празднования Навруз, плакаты со словами: Наурыз, Гульнавруз, Нардуган, Патрих.

**Ход классного часа:**

*Учитель*:

Упал сосулькой март к ногам,
И потекли ручьи по склонам
Навстречу солнцу и ветрам
С неумолкающим трезвоном.
Глядится лес в голубизну,
Вершины сосен запрокинув,
И видит, как, неся весну,
Косяк стремится журавлиный.

Дорогие ребята! Уважаемые гости!

По календарю наступил месяц март. Народная мудрость гласит: март – утро года. Хотя и сердитым он бывает, снегами и морозцем оборачивается, но весной пахнет. 22 марта день сравнялся с ночью. Это день весеннего равноденствия. Праздник Весны!Праздник Навруз – древнейший праздник народов Востока. Об этом светлом празднике мы долгое время почти ничего не знали. Его, как старый ковер, свернули и запрятали подальше. А когда «достали» и «развернули», все просто ахнули. Настолько этот праздник оказался ярким, красивым, веселым и всегда молодым.

С приходом Навруза в Азии встречают Новый год, весну, солнце. И, конечно, к такому празднику тщательно готовятся. Представить его без щедрого дастархана просто невозможно. Таджики называют этот праздник Гульнавруз, крещенные татары – Нардуган, а греки – Патрих. Так что праздник Навруз празднуют все народы Казахстана!

1 **ученик**. В весенний праздник Навруз
Борьба идет меж сил природы,
Играет громко кылкобыз,
Зовет он к дружбе все народы.

2 **ученик**. Айтысы у костра, качели, игры

Народные гулянья
Ты можешь, что угодно выбрать
И победишь достойно в состязаньи

3 **ученик**. Навруз полон солнечных брызг,
Растопил залежавшийся лед
Наурыз к нам явился без виз –
Новый дождь за окошком льет.

**Учитель**.А теперь, ребята, давайте разрешим спор Зимы и Весны.

*Ребята делятся на две команды.*

1 состязание «Кто сильнее?» Две команды приводят доводы и «спорят»:

1. Белее зима – зеленее лето.
2. Хороший снежок посадки сбережет.
3. Замолчи, капель! Прилети, метель.
Тучей снежной потряси,
В царство снега унеси!

1. Весеннее солнышко землю воскрешает.
2. Весной пролежишь – зимой с сумой побежишь.
3. Уходи, зима седая!
Уж красавицы весны,
Колесница золотая,
Мчится с горной вышины.

**Учитель**.Видите, хоть и сильная Зима, но весна сильнее. Во все времена с приходом весны люди связывали свои надежды об урожае, приговаривая:

**Ученик**. Весна, весна красная,
Приди, весна, с радостью,
С великою милостью,
С льном высоким,
С корнем глубоким,
С хлебом обильным. (*Дети исполняют песню «Пришла весна!»)*

**Учитель**: Ребята, прочтите пословицу на доске «Гость в двери – счастье в дом». В этот день двери открыты для всех. Каждая хозяйка хочет быть самой гостеприимной, щедрой, доброй. А, теперь, я предлагаю разгадать кроссворд и прочитать ключевое слово.

1. Столица Татарстана. (Казан)
2. Весенний первый цветок (Күкчәбаш)
3. Дикий хищный зверь. (Бүре)
4. Река, которая течет на территории Республики Татарстан. (Нократ)
5. Сын Казанского хана Сафа-Гирея (Үтәмеш)
6. Музыкальный инструмент с буквой «З» на конце (Кобыз)

**Учитель:** Какое ключевое слово получилось? «НӘҮРҮЗ»! Ребята, вы хорошо отвечали на вопросы, пели, танцевали. Впереди у вас каникулы. Вы живете в мирной стране, у вас счастливое детство. Посмотрите, какие слова написаны на доске:

Вовек не станет пеплом и золой
Все то, что красотой земной зовется,
Пусть будет мирным небо над землей,
Пусть вечно детство звонкое смеется!
*Итог классного часа.*

**Нәүрүз мөбарәк бад**[8]

Шөкер кылдым Ходайга,
Салаватым аңарга,
Мөхәммәд- Мостафага,
Нәүрүз мөбарәк бад,
Шаде бад, шаде бад,
Нәүрүз мөбарәк бад.
Хуҗа эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш килсен,
Нәүрүз котлы булсын,
Котлы булсын, котлы булсын,
Нәүрүз котлы булсын!

Нәүрүз әйттек без сезгә,
Хакын бирегез безгә,
Яшегез җитәр йөзгә,
Нәүрүз мөбарәк бад,
Шаде бад, шаде бад,
Нәүрүз мөбарәк бад.
Хәер бирсәгез безгә,
Ходай бирер сезгә дә,
Сезнең белән безгә дә,
Нәүрүз котлы булсын,
Котлы булсын, котлы булсын,
Нәүрүз котлы булсын




[8] Түгәрәк уен. – 2012. – № 2. – 61 б.












**Рәхим ит, түрдән уз, Нәүрүз!!!**
Казан шәһәре Идел буе районы
73 нче мәктәпнең 4 нче сыйныф укучысы
Фасихова Алия

